– Мин Фаилә Рәшит ҡызы Йосопова булам, мең туғыз йөз алтмыш өщөнщө йылның сентябрендэ шушы ауылда туғанмын. Күп балалы ғаиләдә үстем. Семьяда туғыз бала тәрбиәләндек. Әтей-әнейем дә шушы ауылда йәшәп, колхозда эшләп ғүмер кищерделәр.

Унынщы класны бөткәщ, Шәйковский медицина училищесына уҡырға кердем һәм шуны тамамлап щыҡтым. Анан суң кийәүгә шыҡкащ, шушы ауылда ҡалдым инде. Тормош иптәшем Илгизәр белән икебез дә шушы ауылныкы, бер класта уҡыдыҡ, класташлар.Аннары шушы ғаилә ҡорғащ, шушы ауылда йәшей башладыҡ инде, колхозда эшләдек, төрлө эшләрдә эшләдек. Өщәү балаларыбыз булды. Алар хәзер үстеләр инде, үз семьялары, үз ғаиләләре белән йәшейләр. Шулый, мин хәзер пенсийәдә инде, тормош иптәшем әле пенсийәгә щыҡмады. Шулый, баҡща тотабыз, мал-тыуар асырыйбыз, ҡортлар асырыйбыз, шулыай йәшәп ятабыз. Ауыл безнеке мынан бер өш йөз йыллар, өщ йөз илле – өш йөз етмеш йыллар элек барлыҡҡа килгән. Уфаныҡы нейләрендә архивларында бар, тип Рәфис әйтә ие, тапҡан аны. Шлыҡ тигән йылға булған ҡый безнеке, Верхшлык безнең, Усть-Шлык бар, түбән, безнеке шушы Верхшлык йылғасынан килеп шыҡкан. Элек башта урыс ауылы булған тип тә әйтәләр аны, аннары татарлар килеп ҡалған. Тегерминнәр булған бездә зур, тарттыра торған, өн тарттыра торған сыу тегерминнәр. Без булғанда яңы ауыл ие, аннары Ҡазанка тигәне йөз дә ун бишенще йылларда ғына барлыҡҡа килгән, беззән өстә, без бер колхоз булып йәшәдек инде, анда күпщелек татарлар инде, күрше ауыл, мына безнеке башҡорт, безнең национальность – башкиры, ғәйнә башҡорто тип әйтәләр инде.

*– Ғәйнә башҡорттары теленең лексикаһына байкау яһап үтәйек әле.*

– Ну безнең башҡортлар белән оҡшаш сүздәр күп инде, мәсәлән, былый татарлар тәгәрмәщ тейләр, ә без күләсә тип әйтәбез инде, сездә дә күләсә тип әйтәләрдер, Башкирияда. Радиодан ишеттем әле мин, сездә күләсә тип тә әйтүләрен. Жиләкләрдән өмөжө, шартлама, ансы тау буйда үсә, ҡайын жиләген – жиләк, жиләк тивез инде без, ҡайын жиләге тип тә әйтәләр аны, әме. Шартламасы тау биттә үскәне инде, шартлап тора үзгәндә. Ҡарағатны ҡарағат тибез, ҡарлыған тип әйтмейбез, **эт** борон – шиповник инде анысы, щәнщкеле буғанға. эт борон. Ҡояш ҡорт – Божья коровка, пумалабаш – одуванчик, картуп тип сүләшәбез, тырнауыш тип сүләшәбез, тәпке, изәнас бар өүләрдә, колыбелька бездә сәлей, уҡығанда без аны бишек тип уҡыдыҡ. Без уҡыуын татар китап уҡыдыҡ, Татариянын, Ҡазанныҡын. Тел татарщараҡ сөйләшәң булаң инде, ә былый паспортта башҡорт электән башҡорт тип килгәщ, башҡорт тип ҡалған. Балдыз бар, ҡайнаға ансы абыйы була, хатынныҡы авыйы, кещесе – балдыз, ҡарт әней, ҡарт әтей тип сүләшәләр инде, ҡәйнәней, ҡәйнәтей тёща, тесть была инде, оноҡ – внук, внучка, правнуктар – оноҡшыҡ. Лопух – шөхмит, дегәнәк – кещерткин, талпан – ҡызартҡы, ҡапҡа – ҡапҡа инде, ишек келәһе – бикләмещ тивәйтәбез, яуын яуып китте тивәйтәвез, бармаға кәрәк, барып ҡайтмаға кәрәк тивәйтәвез, тауға менмәгә кәрәк, йылға буйына төшәвез тивез, тәрәзә, түшәм – путулук тип үзгәртеберәк әйтәбез инде, мөйөш, пощмаҡны мөгөш тивәйтәвез, ковёр, палас тибез инде, мендәр, ястыҡ тибез, мендәр ул сиксәнгә сиксән була инде, ястығы зурыраҡ, хәзер ястыҡлар ясымайлар инде, изәнгә икене-өщнө ястыҡ алалар да, матраш жәйәләр дә жоҡлыйбыз ий уланнар күп шаҡта. Ястыҡ зур, бергә бер дә илледән булып китә, икедән дә булып китә, шикелле. Подушка, матрасы да была, менеп ятасың шулый, жәйелеп китеп ятасың, йомошаҡ. Мамыҡтан, жүндән түшәк тә булған, ансы тоже шушы ястыҡныҡы, мендәрнеке нейе, составы, түлке аны матрас урынға салғаннар ансын, түшәк тип сүләшәләр. Ҡалын тоже шулый, күбеп, күпереп тора ул, ну ятҡащ, басыла инде у. Ут ҡабызабыз тип сүйләшәбез. Утны ҡабызырға кирәк. Утны ҡабыз, сүндер, шулый инде. Картупны утыйбыз, аламасын утыйбыз инде, ә картупны жыябыз былый, окончательно жыябыз былый, ә утауы да бар, аламасын утау, картуп алабыз, түгел, картуп жыябыз. Мәтрүшкә – мәтрүшкә, ну аны щәй пешен тип тә әйтәбез, зверобойны аны тоже мәтрүшкә, тип, сары мәтрүшкә тип сүләшәбез, подорожник – яра яфраҡ, миндек – яфраҡ, ромашка жыябыз, йүкә щәщәген жыябыз, цикорий. Ишек алды, үкәртә тип сүләшәбез, щитән – забор, арҡырысы – кәртә, таҡтаны ныгыраҡ алып киттең исә, кәртә, или элек урманнан йоморо ағашны алып ҡайҡаннар, эме, кәртә тип, шуны шитән формада тотҡаннар. Ҡойма тип күпщелек әйтмәйдәр бездә. Ҡазанкада алар инде вообще икенщеләй әйтәләр, алар татарщараҡ ҡойма диеп сөйләшәләр, эпий дә шул бәрәнге, без икмәк, картуп тип әйтәбез, без сыҡтыйбыз тип әйтәбез, алар йылыйбыз, тейләр, щибещ, бездә ҡаз, щибещ бала. Тауыҡ сепейе – щибещ бала, үрзәк бала, ҡаз бала, индюк – күркә, ат колхозда ғына бар, ат ат инде ул. Ҡолон – көлөки тип әйтәбез инде, икесен дә әйтәбез аңҡы. Бийә ат, алаша ат, айғыр, тай была. Жинесенә ҡарап тигән инде бейә ат инәщ ат, инә ат була, алашасы кастрированный була инде, ә айғыр айғыр инде, әнә шуларны без әйтәбез алый. Щыбар атны әйтәләр аҡлы-таплы. Таҡмаҡларны нитмәгә, застольеда килеп шыҡса, щыға инде ул. Ләкәпләрне ололар сүләшәләр ие инде, Әсҡәт абыйлар бар ие бында, шумер тип сүләшәләр ие у затны, шулый, затлап-затлап, күрше ауылда анда һәр кешенең ләкәбе бар. Элегерәк, кеше күп щаҡта, булған инде ул.

*Верх-Шлык (Эщлекбаш) ауылында Йосопова Фаилә*
*Рәшит ҡыҙынан (1963 йылғы) яҙып алынды*

**Ҡантуғанова Гөлфиә Бәдертдин ҡыҙы, 1961 йылғы**



Мин Ҡантуғанова Гөлфиә Бәдертдин ҡыҙы, мең туғыз йөз алтмыщ беренще йылда тыуып үстем. Техникум тамамлап, шушы ауылга эшкә килдем. Шунда кийәүгә щыктым, өщнө балалар үстерәбез. Хәзер инде оныҡлар отпускыға ҡайтып жыйыла жәйге ощорда. Алар белән шулай мал ҡарап йәшәп яттыҡ инде, хәзер пенсийәдә инде.

Инде хәзер йәш тә бара миңке. Ауыл жирендә менә шулай ҡош-ҡорт ҡарап, пенсийәдәбез. Баҡщада бәрәңге, картоп тип әйтәбез инде без, картоп үстерәбез, йәшелсәсен, ҡош-ҡортон, щебиләрне алабыз, сыйыр асрыйбыз-ҡарыйбыз, сөтөн-майын ясыйбыз. Шулай йәшәп ятабыз.

Бу ауыл бик бороңғы ауыл инде бу. Шликбаш, ней, Төнгүк ауылынан килеп, Йосоповлар белән Нурсубиннар мында нигез салғаннар инде. Миңке ирнең дә туғаннары Әжән яҡтан килеп урыннашҡаннар, Ҡантуғановлар, Нурсубиннар, Йосоповлар бу ауылға нигез салыущылар тип сүлейләр. Мында урман булған. Шошы урманны арщығаннар. Арщып жир сөргәннәр. Мында гөрләп торған колхоз болды. Әнә ҡый колхозлар бөткәщ, әле тоже бар анда безнең ней, Исмыкаев Фәнис авый эшләгәндәге фермалары бар. Щәщәләр, иген уралар, складлар, иген эшкәртәләр, эшщеләр эшлейләр, бар әле.

Легенда тип, шушы ағащ урманны кисмәгә килгәннәр мында, Төнгүккә. Шушы түштә ҡайзандыр азан тавышы ишетелгән. Шушы азан тауыш ишетелгәщ, былар мында ауыл булмаға тейеш тип әйткәннәр инде. Аларға шушылай ишетелгән азан тауыш, тип сүлейләр шулый. Мында жиләк-жимеш, урман, саф һауа, шишмә-йылғалар күп, шуңа урыннашҡаннар инде бында. Райондан йыраҡта, йыраҡ булса да мында йәшәүе, мал ҡарамаға, бесән эшләмәгә уңайлы жир. Ана мында безнең Салкын шишмә бар – безнең сабантуй урыны инде. Бик матур урын йылға буйда. Аннан тегенән килә Жәнтимер – Осиновка. Жәнтимер – элек анда урыс ауыл булған, урыс ауыллар беткәннәр инде унда. Шушы ике йылға мында нейгә килеп ҡушылып, тегендә нейгә, Тол йылғаға ҡушылалар инде тегендә, әле Башап йылғаға ҡушылып китәләр. Шул Тол йылға буйда үстем инде мин (йырлай):

Тол йылғасы – ағым сыу,
Йөзә тулған ай.
Йәшлек хәтирәм
Ҡалды синдә, Солтанай.
Айырды безне йыллар,
Ярсыулы йыллар.
Ощращыу көтөп,

Талды сузылған ҡуллар, – мына Мостафа Ноғман авый язған буны. Бездә халыҡ телгә оста. Жырға да оста, бейеүгә дә оста. Ана тегендә Илгизәргә барың әле, алар икесе дә оста, Фәймәсе дә оста, Илгизәргә барың.

Пәрәмәщ пешерәбез, шәңгәсен, эрек шәңгәләр пешерәбез, сөттән ҡатыҡ, сөзмә ясыйбыз. Алар төрлө. Ҡатығын башта ясййсын да аннан шуны торғозоп, сыуы ағып китә, ҡатысы кала. Ҡатысы ҡалғащ, аны сөт бeлән бутатып аны тағы ла шикәр, тоз салып сөзмә ашыйбыз. Күп пещерәбез: щәк-шәк пешерәбез, сездә бауырщаҡ тип әйтәләрме, бездә щәк-щәк. Илгизәргә нищек бармаға, үрәтеймме сезгә

Һуғым һуйыу – башмаҡ суйыу тип сүләшәбез инде, башмаҡ, тана тип сүләшәбез.

Быҙау – бозау, бәләкәйе, ике йәшкә яҡын, ике йәш ярымны.

Ямғыр яуа – яуын яуа.

Йәйғор – Салауат күпере.

Щын башҡортлар белән аралашу безгә ҡыйынраҡ сүләшеүе, но барыбер аңлыйбыз. Барыбер безнең икенще төрлө сүләшеү. Татарщаны да, башҡортщаны да аңлыйбыз без. Башҡортта хәрефләр күверәк, бездә әзерәк.

Ҡызыл эрек ясыйбыз, ҡаймаҡ ясыйбыз.

Кесерткән – кещәрткин тибез ҡыщытҡанны.

Талпан – ҡызартҡы.

Мәтрүшкә – щерки пещин.

Һары мәтрүшкә – сары пещин.

*Верх Шлык (Эщлекбаш) ауылында Ҡантуғанова Гөлфиә Бәдертдин ҡыҙынан (1961 йылғы) яҙып алынды.*

## Елпачиха (Үдик) ауылы

**Аҡбашева Фәнүзә Мирза ҡыҙы, 1960 йылғы**





Алтмышыншы йылда тыуғанмын шушы ауылда, Үдик ауылында, шунда беренше класҡа кердем, шунда уныншы классны бөтөрдем, ну ҡысҡаша әйткәндә, шунда тудым, шунда йәшәдем, хәзер зә шушы ауылда йәшейем, пенсийәдә инде. Мин торговый училищеда уҡыдым, ғүмер буйы, ҡырыҡ өш йыл Росгосстрах компаниясында страховой агент булып эшләдем, хәзер дә эшлейем. Шул ауылда ауыл тормош белән йәшәдек инде, икене ҡызлар үстердем тормош иптәшем белән. Икебез дә шушы ауылдан без, ҡушылдыҡ шунда, бергә тордоҡ, ун туғыз йәштә кейәүгә щыҡтым, ҡырҡ биш йыл торабыз.

Бәхет – тазалыҡ, донъяның тәмен белеп йәшейем тип йәшәү инде, минеңшә, мин үземне нащар йәшәдем тип уйламыйм, нормально, мин үземнең тормоштан бик ҡәнәғәт, балаларым да, Аллаға шөкөр тип тә әйтсәм дә була.

Бездә, например, ҡунаҡтан ҡайтҡанда былай жырлыйлар, элеккеләр жыры инде ул:

Берәү, икәү, өщәү, дүртәү,<br>
Бишәү килдек без сезгә,<br>
Алты, жиде, сигез туғыз,<br>
Унаулап килең безгә, – тип.<br>
Эй Рахмет, Раталитин,<br>
Яратам, ни хәл итим, – тип жибәрәләр.

Эшке ҡунаҡлар була инде, но хәзер сирәгәйзе инде, хәзер кеше артыҡ эшкегә нейтелмәй, элек бит гел ҡунаҡларға йөрөшөп күп булайы, хәзер кеше нищектер иркен йәшәй башладымы, нишектер үз-үзенә бикләнде тип әйтәм инде мин.

Йолалар – бары да бар инде, Ҡорбан ғәйетләрне зурлап үткәрәләр, савантуй шаулап бездә үтә. Быйыл бездә бик зур савантуй булды. Безнең эшмәкәрләр Ғиманутдиновтар Ҡазан артисларын китертеп, шаулаталар ауылны, гөрләтәләр, Аллаға шөкөр! Савантуйда көрәш, туры бағанаға менеү, ҡыйыҡ бағанаға менеп, суға сикереп, әнә, сездең яҡларда белмейем, бездә уы, Татарстанда ниндәй уйыннар бар, йөгөрәләр, волейбол уйныйлар, хәзер яңы төрләр барлыҡҡа килде, мотоблокта ярыштылар быйыл беренче ҡабатны, велосипедта ярышалар, бүләкләр саллый, әләндей зур-зур бүләкләр эшмәкәрләр, саллы – ҡиммәтле была, әйбәт-әйбәт нейләр. Көрәш батырына тәкә бирделәр, ике көрәш – йәш үсмерләр арасында, зурлар арасында булды у, ә решили, йәш үсмер ун биш йәшлек егеткә тәкәне вручать иттеләр инде, Ильназға, бик әйбәт булды савантуй.

Үз урыннарын табып, савыр булып, шул хәр бер нейгә инде, тормош нейгә яраҡлашып йәшәмәгә тырышмаға кәрәк, бер кемгә дә көн итеүе рәхәт түгел, сезнең яҡта да шулайдыр. Нищектер инде савырлылыҡ, түземлелек, үзләренә-үзләре ныҡ булып йәшәмәгә тырышмаға ҡушам инде мин, мин ике ҡызыма ла шулай тип әйтәм, савыр, савыр тивәйтәм, кейәүгә щыҡансыз икә, торың, тивәйтәм, төрлө ғәләмәтләр була ҡый. Миңке зур ҡызымнын, например, ун йыл үзе генә, ире рактан үлде, икене ҡызлар ҡарап тора инде, савыр-савыр тивәйтәм. Бер кемгә дә рәхәт түгел, нищектер яраҡлашмаға кирәк, без ауылда әнә ҡый, шунда малын ҡарап, щибещ-тауыҡларын ҡарап, аҡща юҡ тип ултырмыйбыз инде, йәшәмәгә тырышабыз. Бөтөн жирдә шулый. Мин сездең яҡларда күп районнарда булғаным бар, Шафрановоға ике йыл бардым.

Ҡый тип ҡуша торғайнылар инде без, бардым ҡый, ҡайтып киләм ҡый, безне шуға ҡый татарлары тип әйтәләр. Элек-электән килгән инде ул шушы ауылға, может күрше ауыл тирәләрзә юҡтыр, но біздә гел ҡулланабыз, эме. Без уже шулай воспитаны потому что, хәр бер ауылдың үзенең диалекты була инде ул. Кеше белә сүләшкәндә, әдәбищә сүләшмәгә тырышабыз инде, ә былый үзебезгә сизелмей.

*Елпачиха (Үдик) ауылында Аҡбашева Фәнүзә*
*Мирза ҡыҙынан (1960 йылғы) яҙып алынды*

**Ҡотлобаева Хажирә Әхмәтсафа ҡыҙы, 1941 йылғы**



– Әтейемнең – Ҡотлобаев, әдәби телдә тип әйтеймме, башҡортща да килешә уы, Әхмәтсафа Гәлей улы. Минеке – Ҡотлобаева Хажирә Әхмәтсафа ҡызы. Тормошҡа щыҡҡащ, Искандарова булдым инде. Искандарова Хажирә барыбер шул отчество шул ук. Ҡырыҡ беренще йылның ун бишенще январендә тудым. Инде сиксән ике тулдым. Сиксән өщөнщө йәш белән барам, Аллаға шөкөр.

Әнә йәшәүебезгә дә инде илле өщ йыл, житмешенще йылны өйләнешеп, соң ғына тормошҡа щығып, өщ балалар үстердек, алты оноғыбыз бар.Әнә тегендә фотолар бар, нейләр… ул килене дә бар анда, икәү аның белән утырабыз. Ә семья тағы да ана киленнәр бар, кийеүләр бар. Байбыз. Шатланып йәшейбез, пенсийә алабыз. Но шулый да сәләмәт шикле, ҡартлыҡта тип уйлыйбыз инде, врачлар, дуслар булышалар, балалар ҡарыйлар.

Пенсийә бирәләр, пенсийәбез бик әйбәт. Ризык алалабыз. Балалар менә, алға таба ышанышщ аларға инде. Әлегә гөмөрнө озайтып киләләр, и йөзләренә ҡызыллыҡ китерергә язмасын.

Сезнең белән ощрашыуға насыйп булды. Зур рәхмәт!

«Сандуғащның, мескенкәйнең ҡанатлары ҡайрылған,

Ҡайрылса, ҡайрылған, без дә шулай айырылған», –

тигән элек-элек ҡартларның сүзләре белән әйтәләм. Но мин аны жырламадым да, айрылмадым да, бергә-бергә булырға язсын, туғаннар, дуслар, яҡыннар белән. Тағын ниндей сүзләр әйтеп, сезне шатландыраламдыр. Кирәкмәгән сүзләр сүләсәң дә, соңонан уйласаң да…

Бу яҡларда иң беренще арлар килгәннәр, удмуртлар. Анан сың, шуларның эзләре һаман да әле саҡлана, ҡәверлек бар. Ул ҡәверлектә инде безнең яҡын туғаннарыбыз, энекәшләребез, йорт салып, матур ғына шунда йәшейләр, аны саҡлыйлар, саҡлауға ҡуйылған. Әнә инде башҡа нейләр…башҡортлар килгәннәр инде. Башҡортлардан сың, руслашыу башланғащ бу якта, инде татарлар да. Без тату йәшейбез барыбыз да. Но төрлө милләт кешеләре бар. Барыбыз да бер-беребезне аңлыйбыз. Жирле телдә сөйләшәбез, әдәби телдә мәктәптә генә сөйлейбез. Мында өйдә нищек кирәк – шулай сөйләшәбез.

«Күтәрмә» тип сөйлейбез, «ишек алды»н ишек ал тивәйтәвез инде, «тасҡаҡ» – әнә тотоланған утын ҡуйыла. «Мищ»не мищ тип әйтәбез инде, «тава»ны тава тивәйтәбез. «Ҡалаҡ» тибез. Ағащлар: ҡайын, имән, шоморот, тал, ней, әйткәндәй, зирик, жирек тивез аны, тағы... ащма, щыршы, ҡарағай, нарат.

*Елпачиха (Үдик) ауылында Ҡотлобаева Хажирә Әхмәтсафа кыҙынан (1941 йылғы) яҙып алынды*

**Мозафарова Фәридә Рафиҡ кызы, 1960 йылғы**

– Мин Мозафарова Фәридә Рафиҡ ҡызы, мең туғыз йөз алтмышынцы йылның егерме житенще сентябрендә шушы ауылда тудым, тормош иптәшем – Мозафаров Марат Нәшәт улы, башҡорт Ҡоролтай рәйесе, дүрт балалар үстердек. Үзем утыз ике йыл Үдик урта мәктәбендә эшләнем, уҡыттым инде, тарих уҡытыущысы булып эшләдем инде, хәзер пенсияда. Без татар-башҡорт мероприятиеларында ҡатнашырға тырышабыз, диктантлар әле яздыҡ. Төрлө ниндей эшләр ҡушыла, тормош иптәшем менән бөтөн мероприятиеларға ҡатнашырға тырышабыз. Әле үзебезнең мәщеттә без төзөгән идек «Ятҡыр» группасы, алар белән дә без, бик күп кенә мында безнең грамоталар-нейләр дә бар анда. Без күп кенә нейләргә йөрөп, ауылларға, концертлар ҡуйып жөрөдөк.




Шушыны әйтәсе килә инде, татар, башҡорт булсаҡ та, без бергә-бергә татыу йәшәдек, без бөтөн ғөрөф-ғәдәтләрне үтәргә тырышабыз, бөтөн бәйрәмнәрне саҡларға тырышабыз, үзебезнең балаларға, оноҡларға өйрәтеп ҡалырға тырышабыз инде, кийемнәрде дә, мына бу ҡызыл француз яулыҡ тип әйтәләр инде, ҡартәнейләрдә бар әле сандыҡларда, алар постоянно аны ябынып йөрөйләр ие инде. Ул француз яулыҡ бик йомшаҡ, шелк сымаҡ, натуральный у, бик матур, зур итеп бәйлейләр ие, зур итеп ябып, матур була ие инде

Ну ашлар инде, безнең башҡорт белән безнең менә Пермь башҡортлары оҡшаш, шул уҡ ашларны пешерәбез инде, шушылай уҡ күберәк ит, иткә басым ясала инде безнең бөтөн ашлар, бәлешләр тивәйтәвез инде, мантылар, билмәннәр, пылаулар – барысы да шушы иткә күберәк басым ясап. Менә ун дүртендә без хәзер мында Ҡорбан бәйрәме ясыящаҡбыз, гел мында без мәщеттәге апайлар-авыйлар белән гел шундый мероприятиелар үткәреп торабыз инде, ҡатнашырға тырышавыз бөтөн жиргә дә. Бәлешне күберәк пирожки тип әйтәбез инде, кещерәген ясыйбыз инде, өщпощмаҡ, но мыны да, бәлешне дә ясыйбыз инде. Күп кешелә мишләр бар әле безнең, газ керетелсә дә, мищләрне саҡладыҡ. Ну газда да пешерергә була, но мищләр, ал мищләр бар әле. Уыз бүкмә икенщерәк инде, аны йылға бер рәт ясыйбыз инде, сыйырлар бозоулағащ, но хәзер любой щаҡта ясарға була инде, эрек, эрек-нейдән инде ясарға була, бәрәңгедән дә и эрегенән, именно уыз, сыйыр бозоулағащ инде.

Бу ауыл исеме Елпак тигән сүздән алынған, яссылыҡ жирдә урынлашҡан, яссы – түбәнерәк, щоҡор кевегерәк инде, Елпачиха. Но икенще версиясы бар, ель и пасека тигән сүздән алынған, тигән нейе дә бар. Бер китап бар ие у, русща китап у безнең, нимә аңлата: ғүмер-ғүмергә ҡортщолоҡ белән шөғөлләнгәннәр, бар ие безнең менә Ҡыяртау тип әйтәләр, анда ҡыяр үстерәләр ие, төрлө жимешләр, ҡарлаған, ҡарағат тип әйтәбез без, һәм анда бар ие зур безнең баҡша, ҡарлаған баҡшасы, һәм шунда бөтөн ауыл халҡы, колхозныҡы инде ул, колхозға килеп, например, бер щиләк жыйсаң колхозға, бер щиләк үзеңә жыйып алып ҡайтырға була ие. Менә мин кеш кенә идем, сигез, ун, туғыз йәштәр ие микән, мине әбейем үзе белән йөрөтә ие, жыйып алып ҡайтабыз, анда башта жыйабыз, аннары без алып ҡайтабыз. Шунда ҡорт баҡшасы бар ие, бик зур, шунда эшлей ие бер Нәзи исемле абый, будкасы бар ие, щәй ҡуйып, баллар белән, щәй белән сыйлап ҡайтара ие барыбызны да. Шул

матур жиланда зыярат, безнеке өщ зыярат бар ауылда, бик жәмле ердә урынлашҡан, шул күңелле тау инде, Ҡыяртау тип әйтәбез инде. Менә шундай бик матур жирләр бар. Мына бу ель и пасека тип әйттемме, эме, щырщылар да күп инде анда, эме, видимо, шу ель и пасека – Елпачиха, шунан килеп щығарға тийеш, тип уйлыйбыз инде. Шишмә бар анда, шишмә ағып ята, Салҡын шишмә тип әйтәбез, бик йәмле урын безнең, шунда жийылалар инде бөтөн йәшләр дә, ололар да. Башҡорт исеме Үдик башҡортса да Үдик инде, башҡа исеме юҡ, Үдик «бер тигән»не аңлатҡан, арлар йәшәгәннәр мында, арлар «беренше, бер» тигән сүзне аңлатҡан. Әйтелә инде, менә ауылның уртасынан, теге Ленина урам бит инде, әме, йылға ағып ятҡан, тип әйтәләр, менә шунда йылға булған, тип әйтәләр, арлар йәшәгәннәр, һәм аларның «беренше, бер» тигән сүз аңлата, тип әйткәннәр. Нәрсәгә алай әйтелгәндер, анысын аңлап булмай. Халыҡ эшщән булғандыр, алдынғы, тырыш булғандыр тип уйлыйбыз инде.

Палас бик шәп суғалар ие. Бик матур итеп бездә Ҡунаҡаева Мөслимә тигән апа бар ие, ул мынан бик йыраҡ йәшәмей дә ие, бик оло, ул бик шәп итеп паласлар суға ие. Кешеләргә дә, элек бит туйларға коверлар юҡ ие бит, бөтөн халыҡҡа, ҡыз кийәүгә шыҡса, беренше паласлар кәрәк була ие, сөлгөләр кәрәк була ие, мына шундый щигеп, паласлар суға торған әбейләр бар ие.

Үдик ауылына сигез йөз йылдан күверәк булды инде, сигез йыллығын үткәрдек без аның һәм боронғо ауыллар, иң боронғо ауыллардан санала инде. Ауылыбызда әле үк ике мәщет булған, менә шушы урында булған берсе, янған инде пожарда, берсе дом культура янында, яҡында ғына булған инде. Булған безнең ищеү татар-башҡорт-рус училищесы, мына мынан йыраҡ түгел ул. Ултыра әле ул здание, ике ҡатлы булған, Ҡазаннардан килеп, бик күп шундай уҡымышлы кешеләр уҡытҡаннар инде. Халыҡ уҡырға омтолған, образованный булғаннар, уҡыуға ынтылыш зур булған. Төрлө Ҡазаннарда да, Өфөләрдә дә уҡығаннар инде, менә ата хәзрәт тип Султанайның, ата хәзрәт тип, әле күптән түгел генә анда зур мероприятие булды, мына шундай бик шәп белемле предпринимателләр, уҡымышлы кешеләр бик күп булған. Хажға барыущылар да булған, гөрләп торған ауыл, хәзер дә менә ауыл зур, йәшләр тоже йортлар күп салалар, киләләр, зурая ауыл, көндән-көн тип әйтәсе килә инде. Но без күберәк инде Ҡазанщараҡ сөйләшәбез инде, әдәбишә тип әйтәбез инде, алифба шунан килгәнгәдер инде, алифба буйынща уҡығащ без, Ҡазанща, әдәбищә сүләшәбез инде күберәк. Но үзебезнеке, без былый инде, ней арада әдәбищә сүләшсәк, өйдә әнә барыбер үзебезшә ғәйнә башҡорт сүзләр менән сөйләшәбез инде. Безне күп кеше инде ҡызыу сөйләшә тип әйтәләр инде, ҡызыу да сүләшелмей инде, нормально кевек үзебезгә. Но аңлашыла инде, татарлар да аңлыйлар, башҡортлар да аңлыйлар, но бездә башҡорт апалар, элек кийәүгә килгән апалар бар иде. Алар ғүмер буйы торсалар да, беззә йәшәсәләр дә, тип әйтәбез инде, үз телләрен алар үзгәртмәделәр инде, житмещ-сиксән йәшкә щаҡлы йәшәсәләр дә, алар үзләренщә шушылай сүләштеләр, башҡортща сүләштеләр инде. Но балалары тоже ҡайсы берсенең сүләшәлер инде, но күберәк шушы үзебезнең жирле теллектә сүләшәбез инде Менә килеп шыға инде безнең әзәбишә сөйләшеү белән безнең башҡорт сөйләшеүе, синонимнар кеүек килеп шыға, мына, төрлө сүзләр, мәсәлән, тип әйтәм инде, бик сусадым – тамаҡ кипте тип әйтәбез, эме, аңҡыдым, шу хәтле су эщәсе килә тип әйтәбез, ээме, бик матур әдәбищә әйтәбез инде, ә без инде уғата матур, мына мында бик ҡызыҡ сүзләр бар инде. Мәсәлән, сезгә тоже аңлашылыр инде алар. Но мыны үзегез әйбәтләп тикшерерсез инде, ниткән щаҡта инде (яңыраҡ сыҡҡан «Ғәйнә башҡортларының Барда сүзлеге» тураһында әйтә), бөтөн нимә мында төзөлгән.Бу әле мында тағы яңы сүзләр булырға тийеш, тағын да бу китапны дауам итербез, тип әйтәләр инде, тағын да. Менә өлкән кешеләр булған уахытта әле, күберәк

яздырып, ул сүзләрне юғалтмасҡа кәрәк инде, теркәп ҡалырға кәрәк инде. Мында оло апалар йорт сайын йөрөп, оло абыйлар, бавайлар шушы сүзләрне жыйып йөрөп шушы нейләрне төзөдөләр инде, мында авторлары-нейләре, барысы да язылған.

Әле мында язылған: «Елпачиха. Удик. Удик по-татарски село называется. Раньше здесь жили ары. “Удик” – “единственная”», бердән-бер тигән сүз инде, «они здесь жить начали», арлар, «жить начали впервые, отсюда и название», тип әйтелгән инде, Үдик – “единственная, бердән-бер, беренще”, беренще арлар йәшәгәннәр, мыны әйткән Мансуров Абдрахман, мең туғыз йөз өщөнщө йылныҡы, ул шушы безнеке ветеран войны ие һәм хәзрәт ие, ул оло хәзрәт ие, шушы мәщетне беренще ащуда башлап йөрөүще Мансуров Абдрахман бавай, тип әйтәвез инде, мең туғыз йөз өщөнщө йылныҡы суғыш ветераны, ул озаҡ йәшәде, туҡсан дүрт йәшме, даже туҡсан жите йәшме, шулай вафат булды. Бик тырыш, бик әйвәт бавай ие, менә ул әйтеп ҡуйған инде, «бердән-бер, беренще арлар йәшәгән», тип инде. Анан соң менән Ҡунаҡаева Мөслимә апа тип әйттем бит инде, менә ул әйткән, менә шу палас суғущы әвей: «Это когда начали крестить татар, арские татары бежали сюда. Когда Иван Грозный начал крестить, они бежали, могли и другие здесь жить, могли удмурты, вот у них цифры бер, ике, өщ по-другому звучат “адик, ак”». Менә бер, ике, өщ – “адик”, может, Удик шунан килеп щыҡҡан, тип әйтәләр. «И они были первые, поэтому Удик от Адик – единственные, а по-русски Елпачиха. На кладбище есть их могилы, тех, кто поселился первым. Село Ҡунаҡаево. От Ҡунаҡаевой Муслимы, 1918 года рождения». Менә тағын өщөнщө кеше мында әйтеп ҡуйған, Масадов Хаплахан тигән кеше Үдикнең, егерменще йылның: «Это ары шли первыми в Елпачиху, это имя было Удик, это был рыбак, ар Удик, первый поселился по национальности ар. На горе недалеко есть могила, там ары похоронены». Менә тауның ощонда, ул дүртенще зыярат була инде, и ауылға кереп килгәщ, сул яҡта, анда күргәнсездер, зур зыярат бар, менә шуңа ҡаршы тағын юл кереп китә, анда тоже иске зыярат бар инде, менә шунда күмелгәннәр, тип әйтәләр инде аларны. Барлығы ул зыяратны тағы дүрт зыярат бар, ауыл зур. Менә бу китапта бөтөн нимә бар. Менә мыны, Бардада Түбәтәй мәщетне күргәнсездер инде, әме, түбәтәй формасында салғаннар. Ә бу мәщеткә безгә алдағы йылға утыз йыл була, хәзер менә бу икенще мәщетнең манарасын эшен бөтөргә тийеш, менә газ керетелде, эше бөтмәде әле. Әйбәт кенә жыйылалар халыҡ, бөтөн традицияларны, обычайларны бергә тырышабыз инде, кешене тартырға тырышабыз. Уҡущы балалар да килеп торалар, лагерларда әле, лагерларныҡы килеп торалар, аларға да сүлейбез инде. Мына халыҡны нищектер берләштерергә кәрәк, дуслыҡ булсын, татар, башҡорт, Ҡазан белән, Уфа белән дә, Уфада уҡущылар да хәзер безнең бик күп кенә. Төрлө профессиялар алып ҡайталар һәм эшлейләр. Менә шулый. Уфа бик матур. Уфа белән безнең районыбыз дус булсын алға таба да, жепләр өзөлмәсен, нығысын күберәк, бергә йәшәргә, бөтөн ғөрөф-ғәзәтләрне саҡлап ҡалырға булсын инде. Әгәр зә без өйрәтмәсәк балаларны-оноҡларны хәзер, кем өйрәтер.

*Елпачиха (Үдик) ауылында Мозафарова*
*Фәридә Рафик ҡыҙынан (1960 йылғы) яҙып алынды*

## Искер ауылы

**Аптукова Наифә Хәким ҡыҙы, 1964 йылғы**

– *Үҙегеҙ менән таныштырып үтегеҙ әле?*

– Мин – Аптукова Наифә Хәким ҡыҙы, алтмыш дүртнеке.

– *Ошо ауылда тыуып үҫтегеҙме*?

– Юҡ, минеке әтейләр, әнейләр, әней – Искернең, әтей – Түбән ауылныҡы. Әтей үлгәщ, мында ҡайттым да бу ызбада илле йыл торам инде.



Бу минем ызба. Әтей дә, әней дә үлде, мин үзем генә. Ҡыз Әржәндә кейәүдә. Уланнары икәү, тормошта.

– *Кем булып эшләнегеҙ?*

– Фермада сыйыр саудым. Утыз йыл булды, ана ҡый группа белән киттем мин пенсийәгә.

– *Ауылдың исеме ҡайҙан барлыҡҡа килде икән?*

– Анысын белмейем. Клуб работнигы Илдар белән Инсиә белә.

– *Унда алып бараһығыҙ, эйеме?*

– Ээ, бармаға була.

– *Ауылда кешеләр нимә менән шөғөлләнә?*

– Ферма бар бездә, сыйыр сауалар килгән халыҡ, мин үзем пенсийәдә инде. Уланнар үсте. Әржәндә тора ҡыз.

– *Йәш сакта ниндәй уйындар уйнанығыҙ, нимә менән шөғөлләндегеҙ?*

– Әней белән торғанда мал ҡарадыҡ, хәзер малларым юҡ инде. Үзем генә торам. Бер мал да юҡ, эт-песей дә юҡ, щебещ тә юҡ. Элек лапта уйыннар уйныйбызый болонда, әбәк уйныйбызый, ҡащымыщ уйын уйныйбызый. Башҡа уйыннарны, кемнең нимә уйныйсы килә... Клубҡа щығабыз ий кищке уйынға.

– *Ниндәй бейеүҙәр бейей инегеҙ?*

– Татар бийеүләр, башҡорт бийеүләр, төрлө жырлар.

– *Ауылда ниндәй милләт кешеләре йәшәй?*

– Ауылда анда төрлөсө бар, урыслар да бар, башҡортлар да бар, немец белә английскийлар ғына юҡ анда, бары да бар. Килгән халыҡ эшлей фермада.

– *Еләк йыяһығыҙмы?*

– Быйыл ҡоролоҡ булғащ, йоҡ, жиләк тә йоҡ, шартлама да йоҡ. Шартлама тип сүләшәләр бездә, ә сездә, Уфа яҡта, ҡайсылыйдыр, белмейем мин ансын.

– *Һауыт-һаба исемдәре нисек атала икән? Тарелканы нисек әйтәһегеҙ.*

– Тарелка тивез, тәринкә, тип тә әйтәләр, щоҡор, самауар, таба.

– *Балғалаҡты нисек әйтәләр?*

– Ҡалаҡ. Ҡайсыдыр балҡалаҡ, тей, мин ҡалаҡ тивәйтәм, щәй ҡалаҡ, аш ҡалаҡ тип сүләшәләр. Ҡазанны ҡазан тейләр.

– *Лягушканы нисек әйтәләр?*

– Щавып йөрей торғаннымы? Баҡа бала тивәйтәләр, баҡа тип тә әйтәләр.

– *Туғанлыҡ атамалары нисек?*

– Әтей, әней, ҡартәней, ҡартәтей, зур бавай тейләр, зур әвей тейләр.

*– Тетя, дядя тигәнде шулайтып әйтәләрме?*

– Ээ, апа, абый, тейләр, энекәш, сеңлекәш, ҡәйнәней, ҡәйнәтей, ҡода-ҡодағый, балдыз тип әйтәләр, балдызым-ялғызым тип жыры да бар.

*– Йырлайһығыҙмы әллә?*

– Йоҡ, мин алый йырлағаным йоҡ.

*– Таҡмактар иҫтә ҡалмағанмы?*

– Йоҡ, инде ҡартайдым, алый, инде алтмыш булам, Алла бирсә.

*– Ярар, Аллаға шөкөр. Йөҙгә лә етергә булһын инде.*

– Амин, шулай булсын.

*– Үләндәрҙең атамалары тураһында һөйләшәйек әле.*

– Үләннәрнең исемен белмейм мин.

*– Ҡаҡыны нимә тейләр? Ҡымыҙмы? Ҡымыҙ бармы бында?*

– Бар ие, сары щищкәле, мин төрткөләп бөттем, баҡщада йоҡ миңке. Көрәк белә төртеп жыйдым, арщып.

*Искер ауылында Аптукова Наифә*
*Хәким ҡыҙынан (1964 йылғы) яҙып алынды*

**Мөксинова Зәйнәп Минниәхмәт ҡыҙы, 1933 йылғы**

– Мөксинова Зәйнәп Минниәхмәт ҡызы. Мең туғыз йөз утыз өщөнщө йылның сигезенще майында тудым. Тау ауылда тудым, без мында килеп урынлышҡан кешеләр суғыш уаҡытында. Әтей армияға китте, без алты балалар ҡалдыҡ этейдән, анан соң утынға йыраҡ, утын ташый башладыҡ, этейнең запаслары бөттө, эпейләр бөттө. Шунан соң Искердә утын яҡын, тейләр, шунда бер бавай килде дә, барың, тей, ызбаны алыштырабыз, тей, әвей, тей, инде әнейгә әйтә. Балаларны интектермә, тей, йыраҡтан утын ташытып, тей.



Шуның өщөн без мында күщтек ҡырыҡ өщөнщө йылны. Әнән соң этей суғыштан ҡайтмады, үлеп ҡалды.Әнән соң этей суғышҡа киткәщ, ике апаны нәрәткә алып киттеләр, оло апа белә кеще апаны, анан абыйны ФЗО-ға алып киттеләр. Без тағы өщ балалар ҡалдыҡ, уаҡтан-уаҡ. Әтей киткәндә, мин сигез йәш былып ҡалдым, иң кещкенәсе этей киткән көннө туып ҡына ҡалды. Мында Искергә килдек тә, Искердә урынлашып киттек. Менә шунан башлап гел колхозда, колхозда. Ҡырыҡ өщөнщө йылны өщөнщө класҡа уҡымаға кердем, өщөнщө класны бөтөрдөм ий, фермаға щущҡа көтөүгә эшкә кердем, щущҡа ҡарадыҡ ике йыл. Житенще класны бөтөргәщ ий, щущҡа фермада эшләдек. Әнә үзебез ҡарадыҡ, үзебез

көтөүләрде, үзебез эшләдек шунда. Анан соң укымаға китәм, тидем, китәргә өс кийем жук, ашарға әпей жук, шунан соң колхозда ҡалып киттек. Колхозда әнә ғүмер буйы, ҡартайғанщы, быйыл әнә туҡсан йәшне үткәрделәр. Быйыл сигезенще майда балалар килделәр дә ана, туҡсан йәшемне үткәреп алдылар. Вот шулый эшләдек тә эшләдек колхозда. Бөтен нәрсәгә без уң ҡул теймей ҡалмады, суғындыҡ, сyктыҡ, урдыҡ, пещене щаптыҡ, жыйдыҡ фермадан соң. Щәщка көтөүдән туктағащ, бозоуға ҡуштылар, анан соң бозоу ҡарадым фермада, бозоу ҡарый торғащ, кейәүгә щыҡтым, кейәүгә щыҡҡащ, бала тапҡанщы фермада яттым. Анан бала тапҡащ ҡына фермадан күщеп киттем инде. Анан соң гел колхозда, колхозда, и то подменнар алалар ий.

*– Нимә ашап үҫтегеҙ?*

– Иииий, ашыуны аны, оят былыр, әйтсәң. Пещен-салам ашадыҡ, анан соң щерек бәрәңге, щерек бәрәңгегә китәбез ий, алтышар-житешәр щаҡрым жиргә китәбез ий. Щиләк алабыз, көрәк алабыз ий, ҡайда бәрәңге ҡалған, шунда ҡалмағаны ейдек. Анда әле ул суда инде, Толно щыҡҡанда, су аша щығабыз. Башта алып китteләр мине апалар, мин у щаҡта әле кещкенә ие әле, ун ғына йәш ий, әйдә, әйдә, ҡызым, тейләр, аппарабыз, тей, әней инде өйдә барысын да ҡарап ҡалды, балалар ҡарап ҡалды, маллар ҡарап ҡалды, маллар ҡарыйбыз, сыйырлар, кәжәләр, сарыҡлар бар алый, әней аларны ҡарап ҡалды да, мин киттем апалар белә. Бардым, сыуны щыҡмаға ҡурҡыщ, аға инде шундый нығитеп яз көнө, бу әпрелнең нищәселәредер ие инде, ищеү генә бүрәнәсе генә ҡалған Тол ҡырда, шунда бөкәйләп щыҡтыҡ, аға ие сыу, бүрәнәгә тейер-теймәс тора, шуны щыҡтыҡ, болонға щыҡтыҡ, тувыктан башлап тағы сыу, тауға ҡәдәр, ярты щаҡрым бардыҡ инде у, тауға щыҡтыҡ, щаваталарны щығарып ҡоротток та киттек, үәт, шулый, у щаҡта щерек бәрәңге ашадыҡ. Анан соң щерек бәрәңгедән туктадыҡ, пикан, ҡымыз, ҡузғалаҡ, щеберкәй, анан көзгә щаҡлым пещен ашадыҡ. Щеберкәй нимә тип аталадыр русща, мин белмейм, аның күкәйе дә бар, сабағы да бар, күкәйләре аның эре дә, шушындый йоморткалары бар, баллы у, баллы щеберкәй. Үәт шулый, ҡуянҡолаҡ, инә яфраҡлар, алары яфраҡ ҡына инде мындый, шуларны ана, шу көзгә щаҡлым пещен-салам ашап үстек. Ә бищ йыл ипий күрмәдек, бер ниндей ипий жоҡ, бирмей колхоз, барысы да хөкөмәткә китә. Ҡуянҡолаҡны да белмейем урысщасын, яфраҡ ҡына уы, шулый яфраҡ, гел яфраҡ үсә, зур былып үсә уы, алар пикан кевек у инде, пикан кевек. Балтырған ашадыҡ, ансы игенще, алар бит әллә нищә төрлө. Анан щәйгә кишер, сөгендер, шуларны ҡайнатып эщтек, щәй жоҡ, керосин жоҡ, шырпы жоҡ, иртән торабыз, кемнең төтөнө щыға, шунда китәбез щиләк күтәреп за алмаға, ә үзебез анан соң жәй көнө әкәлә жыйабыз, щыршы әкәләсе, күркәләр жыйабыз да, мишеккә, ҡапҡа тутырып, ҡышҡа әзерлейбез, штобы жөрөмәскә. Анан мищнең алдына ҡуялар ий, ҡуя ие дә әней иртәнгә щаҡ шунда күрәлеп ята у әкәлә тейгән. Мына шулый йәшәдек инде, ҡызым. Эээй, ауыр булды инде у щаҡлар, белмейем инде, нисек йәшәгәнбездер, үлделәр инде кешеләр ащлыҡтан, бик күп кеше үлде. Менә шулый без исән ҡалдыҡ. Алтыбыз да исән булдыҡ, анан соң әней сиксән ике йәшәде, апа берсе житмеш сигез йәш йәшәде, оло апа туҡсан ике йәш йәшәде, авый сиксән биш йәш йәшәде, хәзер тағы сеңелем бар, сиксән дүрт йәштә йәшей, Миңжибәр, анан соң кещкенәсе сиксән ике йәш, миә туҡсанға тулды инде.

*– Оҙаҡ йәшәүҙең сере нимәлә икән, Зәйнәп апа?*

– Белмейем инде, саф һауада күп эшләдек инде, саф һауада йөрөү дә файда китергәндер, ээ. Анан соң әнә ҡый әней намазын ҡуймады, уразасын ҡуймады, безне дә ураза тотторды, намаз укытты, намазны укымый кищтән дә щыҡмадыҡ, үәт. Әнә шунан соң

нейдән ҡалған безнеке барыбыз да инде алый нейне, динне ташламыйбыз, тигән сүз инде. Үәт шундый ғәләмәтләр.

*– Өйөгөҙ бигерәк матур, ремонтты кем эшләне, балаларығыҙмы?*

– Балалар, балалар ҡарыйлар алар барысын да. Оло ҡызымда торам, өүдә бер үземә өүне ҡыздырмыйым, ә уртанцы ҡызым мында күршедә тора, уртанцы ҡыз белә жәйне аның белә торабыз инде. Алый балаларым әйвәт, туғаннарым әйвәт, барсы да бергә торабыз. Һер ниндей дә тауыш-ғауға жуҡ буздә. Күршеләрем дә әйвәт, алый барысы да, обижать иткән кеше жоҡ, былмады, ээ. Алый грамоталарым да бар азыраҡ.

*– Таҡмаҡтар, йырҙар, мөнәжәттәр беләһегеҙҙер әле? Йырлап ишеттерерһегеҙ, бәлки?*

– Аларны элек укып жыялмый да соң мөнәжәтләрне, хәзер мә инде аз беләм инде, аз беләм, онотолоп бара. Мин «Саҡ-Суҡ бәйете»н жырлыйым ий, гел жаланда әней мине жырлата ий башта, аның языуы да бар мында, шуны жырлап йөрөйөм ий, гел әнейнеке шу «Саҡ-Суҡ бәйете»н:

Бардым урманға, жиләкләр пещкәщ,
Әнкәй жылыйдыр, исенә төшкәщ.
Мәзрәсәләрдә китап киштәсе,
Әнкәй ҡарғаса, безгә нишләйсе.

Ике баласын әнкәйе ҡарғап ощорған, алар ҡоторошҡаннар, шуның өщөн, әтейләре мәщеткә киткән шу щаҡта, мәщеткә киткәщ, әнейе әйткән, саҡ-суҡ булың, тигән, шу саҡ-суҡ булғащ, иртән торғаннар да, иртән тороуға ике баланың ике яғына ҡанат үсеп киткән. Иртән торғащ, әнейләре дә, әтейесе дә хайран ҡалып, ҡарап торғаннар шу балаларға. Ощоп киткәннәр өүдә, ощоп жөрөйдәр, тей, ишектән щығыр тишек тапмыйлар, тей, анан ишекне ащып жибәргәщ, ощоп щығып киткәннәр. Менә шулар урманға киткәщ, урманда йәшәгәннәр, тей, саҡ-соҡ кәкүк была инде уы. Анан соң улар бик озаҡ ҡара урманда жөрөгәннәр, шуларны ана язып ҡуйып жыйғаннар инде, «Саҡ-Суҡ бәйете» бар, сездә дә бардыр у.

*– Тағы берәй ҡыҙыҡлы әйберләр һөйләгеҙ әле беҙгә. Ауылдың тарихы буйынса, бәлки, нимәлер беләһегеҙҙер?*

– Ауылны нимә, ауылны мин белмейем. Искер ауылы элек-электән булған мында, алар, Мөҡсин бавай белә Көщөк бавай жау щаҡта килеп урнашҡаннар мында, шушы щоҡорға, мында ҡащып урнашҡаннар суғыш уаҡытында, шунда йәшәгәннәр, менә шунан таралғаннар, өщ йөз илле йыллыҡ тип китапҡа да бастылар инде аны, өщ йөз илле йыллығын белеүще юҡ инде, ҡай бер кеше беләдер инде, белмейем мин, әнә шунан башлап барған инде, орлоҡ алғаннар шунда, йәшәгәннәр, ээ.

*– Ауылығыҙ матур. Шишмәгеҙ бар, йылға бар...*

– Алый әйвәт. Мин шушы шишмә буйда үстем, шишмә буйда ҡартайдым, шишмә, ауылға, ана, тормошҡа щыҡтым, тағы шишмә ҡырға урнаштыҡ. Ал шишмәне без әнә жәй буйы үзебез ҡарап, тәрбиәләп тордоҡ, хәзер инде юҡ инде, мин ҡартайдым, башҡа тәрбиәләүще юҡ, шишмә дә ҡартайды, мин дә ҡартайдым. Ғүмер үтә.

*– Ауылға бәйле легендалар бармы? Һуғыш уаҡыттарына бәйле тарихи ваҡиғалар барҙыр, бәлки? Революция, Граждандар һуғышы йылдарына ҡағылышлы нимәләр барҙыр?*

– Аҡлар белән ҡызыллар суғышҡаннар. Мына шушы Ҡарағай тау баштан теге яҡтағы тауға суғышҡаннар ике арада, берсе яҡта аҡлар булған, берсе яҡта ҡызыллар булған. Әнә шу щаҡта тау араларда үлгәннәр инде алар ҡайсылары, аҡлар белә суғыш уахытта. Безнеке әтей дә ана шу щаҡта, аҡлар белә суғышҡан щаҡта, әтей дә суғышҡа барған. У атлар, ат белә

суғышҡаннар ҡызыллар жаҡлы булып, анан соң шушы суғыш уахытҡа житкәщ, әтейне солдатҡа алғащ, әтейнең күзе суҡырайды, күзенә аҡ төштө ие, ҡырығы йәш ий, шу щаҡта әрмийәгә киткәндә, мин, тиән була, ҡайтам кищкә ҡәдәр, тиән була, әтей әйтә, мине, тей, суҡыр кешене алмыйлар, тиән була, уң күзе суҡыр инде, күзенә аҡ төшкән. Командиры әйтә, тей, атып ҡарале, тивәйтә, тей, атҡан, туп-туры итеп атҡан, төз итеп, атҡан да, ах такая маладис, кавалерист, старший кавалерист, тигән да алып киткәннәр, менә. Старший сержант булып үлгән инде ҡырыҡ өщөнщө йылны, Ставрополдәме шунда, похоронкасы килде. Эээй, бик ауыр булды инде әтейсез, әтейсез бик ауыр булды, кеше әтей тигәндә, безнең дә әтей әйтәсе килә ие инде, ә әтейсезләрне мысҡыл итәләр ие алар, хәйерщеләр, тейләр ий. Безгә таба анда баллап ҡараущы да булмады, хәйерщеләр былар, аларның әтейләре суғышҡа киткән, тигән кеше юҡ у щаҡта. Хәзер ауылда ҡалған бавайлар бар ий, алар да йәшерәк инде, аларны нейгә жибәрмәгәннәр, суғышҡа, ҡайсы плотникта ҡалған, ҡайсы фермада завфермой булып, заведующий складта, ҡарауылда, шундый ҡалып киткәннәр дә әнейләрне ниткән булалар ий, бөтөн жирдә уланнар, хатын-ҡызлар эшләделәр, бер ирләр дә басыуда күрмәдек, үәт хатыннар олораҡлары пещен щавалар ий, кәвән салалар ий, без, уаҡлар, жыябыз ий, тырмыйбыз, щәщеү щәщәләр ий апалар, ә безгә тырнауыщ бирделәр дә, тырмыйбыз, щәщкән нимәне орлоҡларны күмеп барың, тип, тезелешеп китәләр ий, үәт, кәкре бавайлар бар ий, кәкре бавайлар, әвейләр бар ий, алар да щығалар ий, ҡартлар.

*– Үгеҙ егеп эшләү юҡ инеме?*

– Суғышҡа ла сөрәләр ие алар, тырматалар ий, суҡа сөрәләр, алар житешмейләр, шу өщөн эщмәгә апалар йөрөйләр. Әле орлоҡлар житмей, орлоҡларны нейдән ташыйбыз, мынан алты щаҡрым жирдән күтәреп, шунантын башлап нейне, суны телеп щығабыз, анда мин дә бардым шу кутумка белә, аны үлщәп, складтан үлщәп бирәләр, мында килгәщ, тағы үлщейләр, теге ашамасыннар, тип, кәметмәсеннәр, тип. Ә мында орлоҡларны да күтәреп ташыттылар, шундый-шундый апаларға бик ауыр булды, уланнарға, азыраҡ ун – ун бер йәш булды исә, алар бары да басыуда булдылар, ә кещкенәләр алар отоуға жөрөйләр ий, алар, кещерәкләр, кещкенә эш эшлейләр, зурыраҡлар – зурыраҡ, берсен дә ҡуймыйлар ий ауылда.

*– Ураҡ менән ура инегеҙме, комбайн юҡ инеме?*

– Башта ураҡ белә урабыз ий, комбайн бар ий, комбайн соңодан ғына бирәү генә килде уы, служный машина килде анан соң, служный машинада ҡырда урап бөткәщ, көлтәләрне жыйып, кәвәнгә салалар ий, озоон иттереп, шу кәвән ҡырға служный машина килеп туҡтый да, шунда суғалар, өщ-дүрт апа машинаға биреп тора, ә без уаҡлар, кещерәкләр, көлтәне аларға биреп барабыз, алар ҡайсы көлтә бауын кисә, ҡайсы машинаға биреп живәрә, өщ-дүрт апалар. Ә безне тағы төнгә алып ҡалалар, төнгә анда ипий бирәләр, берне шундый ипий алып килә ие дә бригадир, шуны былый дүрткә бүлә дә, безгә бер өлөшөмө, апаларға – яртысын, ә комбайнерға берне биреп ҡуя ие. Шу ипий өщөн төннә сәғәт икегә шаҡ суғынабыз, үәт ҡараңғыда ғына без ҡайтып китәбез, анан соң апалар алар көндөз генә эшлейләр, аларның эшләре күп, балалары күп, алар ҡайтып китәләр, анан өщ-дүрт апа ҡала ие шунда, машина алда, безде ул машинаға жибәрмейләр ие, уаҡларны, мына шулый суғындыҡ.

*– Косилка, молотилка, сортировка, веялка, тип йырламаныгыҙмы унда?*

– Эээй, жырлағаныбыздыр инде анда, күвинде у жырлар. Әәә, буйы белә, ээ, малайлар да жырлашалар ий, без дә жырлыйбыз ий, ансы онотолоп бетте инде хәзер.

*– Тула, кейеҙ һуҡтығыҙмы? Кейеҙ итек, аяҡҡа кейәләр бит?*

– Әәә, тула щүңкә, эйе, суҡтыҡ, киндер суҡытыҡ, анда, нейгә, бер машина, бер ат йөгө, житене эпкилеп аудардылар, әнә мин шу щущҡа көтөүләре жунлыйым ий инде кещкенә щаҡта. Әней киндер суға, колхозға мишек тегеп бирә, әнән соң аларны тегеп, халыҡларға тегеп бирә, ауылда тегеүще юғый, әней тегеү тегә ие. Төнө белә намаз уҡый, көндөз эшлей ие уы. Анан соң безгә дә киндер күлмәк тегеп бирде, өстә киндер күлмәк, аяҡта киндер ыштан, башта яулыҡ, ней булғащ, жоҡараҡ итеп суғып бирә дә, безгә сырлап, тегеп бирә ие. Пинжәк тә киндер ий. Үәт киндердән кейеп йөрдөк. И жаңғыр жауса инде, бөтөн тәнне ашый, ҡып-ҡызыл була, киндер ышҡый, тәнне ашый. Тула суғабыз ий, сарыҡ ҡарағащ, без ойоҡбаш бәйлейбез ий, солдатларға ойоҡбаш бәйләдек, бармаҡбаш, бармаҡсыз бийәләйләр бәйләп живәрдек аларға. Әнә шулый. Әле хөкөмәткә эсетне сатабыз сыйырның, сыйыр бозоулый, сразы сөтөн колхозға сдавать итәбез, хөкөмәткә. Әнән тауыҡ ҡарасаҡ, йоморткасын сдавать иттек. Ищеү сарыҡҡа сөт салдылар йөз литр, сарыҡҡа түләдек, кәжә ҡарыйбыз ий, ярый, кәжә беле үзебез туҡланабыз ий, бәрәннәрен суйып ашыйбыз ий, сөтөн үзебез эщәбез. Ә бозоуды иткә сдавать итәбез, ҡырҡ кило ит түләмәгә кәрәк, өщ йөз тәңкә займ салалар. Менә у уахытта бик ней ие, хөкөмәткә. Анан аҡща йоҡ, шул нейләрне сатып, мызар итеп, займ түлейбез, теге итләрнеме-мазарны сатабыз да, көзгө бәрәннәрне-мәрәннәрне, сыйырны сатып, аҡща ясап, түләмәгә кәрәк, обязательно. Киләләр, сорыйлар.

*– Ауылда ниндәй милли йолалар бар?*

– Ауылдамы, хәзер инде барсы да сөйләгәндер әле.

*– Йәштәргә ниндәй теләктәр теләр инегеҙ?*

– Балалар таза булсыннар, ныҡ булсыннар, динне үрәнең, дин сабаҡларын тотсоннар, эшләсеннәр, таза булып, озаҡ-озаҡ, ғүмерләре таза, озон ғүмерле булсыннар балалар барысы да, тигез ғүмердә, әтейле-әнейле булсыннар, бергә-бергә тиң ғүмер белә йәшәсеннәр. Аллаһы тәғәлә бәрәкәтен бирсен, әжәлләргә сабыр бир, донъжаларға тазалыҡ, именлек, саулыҡ, суғышлар бетсен, суғышлар булмасын, ҡайғы-хәсрәт күрмәң, Аллаһы тәғәлә шатланып йәшәмәгә насип итсен. Уҡыуларыңыздың файдасын күрең, тел ащҡыщларыңызды бирсен, тәүфиҡларыңызды, бәхетләреңездә бирсен, тәүфиҡлы, бәхетле балалар үстереп, тормошларға щығып, тәүфиҡлы, шәфҡәтле балалар, жәмәғәтләр бирсен барысына да. Тиң ғүмер биреп йәшәмәгә насип итсен, бергә барың, бергә тороң, бер-берең белә ҡартайың. Без әнә бергә тордоҡ, бергә ҡартайдыҡ, илле алты йыл йәшәдек.

*– Зәйнәп апа, боронғо таҫтамалдар, сөртеүләр юҡмы?*

– Әәә, мендәр тышлар ғына ҡалды, һә аларны сатып бөттөк инде нейдә, суғыш уахытта, тастамалларны, өстәл явыулар, элекке әйверләрме-нейләр, тәңкәләре бар ие әнейнең, түшләре тулы ие, аларны саттыҡ, щулпылар, ҡолаҡ сырғалар... Элекке әнейләр бит бай булғаннар, алар бит үзләре иген урғаннар, иген суҡҡаннар, үәт шуның өщөн алар байлар булғаннар, хезмәтщеләр алғаннар. Сигез сыйыр бар ие, тей, өщәү ат бар ие, тей, әле анан соң ҡартәтейләре хәзрәт булған, әней ҡартәтейләрендә йәшәгән, әнейе үлгән, әнейенән ярты йәш кенә ҡалған, әтейенән сигез йәштә ҡалған, ансы суғышҡа китеп үлгән. Щулпылар, ҡолаҡ сырғалар, балдаҡлар-нейләр, алар берсе дә ҡалмады, барын да саттыҡ. Түштәге тәңкәләрне дә саттыҡ, аның шушынан ий әнейнең тәңкәсе, кещкенә щаҡта мин аны уйнатам ий, концертлар ҡуймаға жөрөйбөз ий, клубҡа, ҡощаҡҡа алып менәм ий. Анан соң ащлыҡ башланғащ, байлар алдылар. Байлар бар ий күрше-тирәләрдә, әтейләре бар, әнейләре бар, алар байлар ий, алар икмәк ашыйлар ий, без аларның икмәкләрен күрмейбез ий. Икмәкләрнең исен борон белә генә иснейбез ий ызба төпләренән үткәндә, үтеп китәбез ий боронно тартып. Шул байларға ғына сатып бөттөк инде.

*Искер ауылында Мөксинова Зәйнәп*
*Минниәхмәт ҡыҙынан (1933 йылғы) яҙып алынды*

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы, 1967 йылғы,**
**Мөксинов Илдар Әүхәт улы, 1966 йылғы**



**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Мин Барда районының түгел инде үзем, туған яғым минең Октябрьский район, бы яҡныҡы түгел, мында килен булып ҡына килдем. Инсиә Муксинова Советовна. Янапай ауылы, Октябрь районы, Пермь өлкәсе. Мында инде килен булып килеүгә утыз биш йыл быйыл, утыз биш йыл ултырам, клубта завклуб булып эшлейм инде уже егерме йылдан күберәк, егерме өщ йыл эшләүгә. Халыҡ белән бик әйбәт эшлейбез, но хәзер кеше азайзы инде безнең ауылда, элек, элегерәк кеше күберәк ие ауылда, йәшләр дә күберәк ие, клубта да күберәк була ие кеше, хәзер... Клубта нәрсә, төрлө мероприятиелар үткәрәбез инде, күп үткәрәбез бәйрәмнәр, мына Наифа апа да килә безнең бар бөтөн бәйрәмнәргә. Берсен дә ҡуймый. Ололар белә дә, балалар белә дә үткәрергә тырышабыз бәйрәмнәрне.

Но безнең кеше аз инде ауылда, аз. Кеше әз. Концертларны, фольклор, фольклор коллектив бар безнең «Ҡарағай» тигән, оло апалар йөрөй инде, күп түгел инде, биш-алты апалар шулай йөрөйбез, үрәнәбез. Мына «Турғай» тигән коллектив жыр, дүрт-биш апалар. «Турғай» ансы. Жырлар хәзер бик шәп, элегерәк биейләр үрәнәбез ие, хәзер бик шәп биеп жибәрәлмибез, ней, шул жырлар, әкрен, ней, фольклор, нейләр.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы**: Бәйләнәләр, щигенәләр.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Тағын нәрсә, бәйләнеү кружок бар безнең, шунда йөрөйбез йыш ҡыда. Бәйләйбез төрле…

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Тюбитей басасызмы...

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Тюбитейны юҡ, аны күп басалмадыҡ. Ҡалфаҡ щигеп алдыҡ бер аз. Тюбитейға андай осталыҡ бик шәп юҡ. Бәйләйбез төрле нейләр, кещке, зур әйберләр бәйләмейбез, кружок, нейләр урындыҡҡа, әйе и аяҡҡа щитек бәйләдек матур. Сапожки инде, бәйләнгән сапожки. Ну сапожки инде бәйләнгән, биегәндә кийәбез инде, ыспай итеп бәйләдек тә, щәщәкләп матур итеп, нейдә, интернеттан ҡарап үрәнеп жыйабыз. Төрлө ниндей нәмә килешә безгә, ниндей ыспай әйберләр бар, шуны үрәнәбез инде, зур әйберләр бәйләмейбез.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Газетаны щирмап ясап жыйасыз да әле.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Ансын Рәсимә.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Рәсимә ясай, ансын Рәсимә исемле хатын-ҡыз.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Из газетных трубочек, плетение из газетных трубочек. Ансын бер апай ясый инде безнең мында, ул үзе заниматься итә инде. Без артыҡ нитәлмибез ансын. Безнең түземлек житмәй. Бик матур итеп оста жыйа у, но аның әйберен кәрәк кешегә генә ясап бирә инде, былай бик шәп ясап жыймый. Солдатларға жибәрәлмәдек бер дә алый, ул хәтле солдатларға жибәрерлек итеп бәйләмәдек.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Уйламаған жирдән әллә ниндейсез булдыҡ әле. Наифә, син нарочно алып килдеңме ҡунаҡларны? Былар жоҡлап ятҡа щаҡта, тип?

Мин үҙем шушы урамда тыуған кеше инде. Миңке йорт теге яҡта, туған йорт, үзем быяҡҡа щығып, ызба-йорт ясап торабыз хатын белә бергәләп нищә йыллар инде. Икене малайлар үстердек. Ике малайлар да военный тип әйтмәгә кәрәк инде. Берсе – контрактник, берсе – мобилизованный.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Икесе дә СВО-да. Берсе ҡайтты әле генә, кещкенәсе ҡайтты әле, зуры шунда.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Минең исемем Илдар, Муксинов Илдар Әүхәт улы булам. Мең туғыз йөз алтмыш алтынщы йыл, егерме алтынщы ноябрь.

Искир тип, иске жирем тип булған инде уы. Иске жиргә элек булған, безнең ауыл бында уҡ булмаған инде, торғаннар да күщеп киткәннәр. Ней бында Толтыр тигән жылға булған, әме. Толтырныҡы жылға аша хәзер у, был яҡҡа щыҡтың исә йылға аша, йылға аша щыҡтың икән, Толтыр тип әйкән йылғаны щыҡтың исә, Осинский район була инде. Элек татарларныҡы доньялары, илләре шунда булған инде, шул яҡта торғаннар өщ йөз илле йыл элек, зыяратлары булған Шәрмәтә тип әйкән ауылныҡы нейендә, тауҡашта инде. Аны урыҫлар сөргәннәр дә жир ясап ҡуйғаннар. Татарларны ҡуғаннар, анан соң мында Расстание тип әйкән ауыл үзләре ясағаннар, Искир йорт тип әйткән жир була ие элек, Искир йорт. Шунантын бы яҡҡа күщкәннәр инде, алты йылға буйда булған тигез жир, ну таулы жиргә татарларны ҡысыҡлап ҡуғаннар.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Пуғащев яуы заманында.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Мына беҙ башҡорт тип язылған беҙнеке паспортларда.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Ну элек язылған ие. Хәзер язылмый.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Хәҙер язылмый.

– Һеҙ бында ҫ, ҙ менән дә һөйләшәһегеҙме?

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Мин, ней, бы яҡныҡы түге шу, бы яҡныҡы бик шәп сөйләшмейм. Безнең яҡта алай сөйләшмейләр. Ул бы яҡтағыраҡ сөйләшә инде.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Ҡатыштыҡ инде, мына нейдән, Октябрьский районныҡы ҡый у.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Безнең яҡта татарлар, былай башҡортлар түгел бездә. Әйе, татарлар.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Шулый, әнә ҡый күщеп утырғаннар, әле нищә, ун жыл элек, ун жыл булмый, ҡый әме, ике мең ун дүртенще йылда өщ йөз илле йыллығын үткәрҙек сабантуйҙа ауылныҡы. Төрле үҙебеҙнеке фамилиялар ниҙәр үҙләренеке иптәшләрен жийып. Ну туғанлар туғанлар инде: Муксиновлар, Кущуковлар, Тайсинлар затларын йыйып, нәҫелләрен жиелып инде бөтөн районнан ҡайҙа килеп шулый сабантуй үткәрҙек ие.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Шәжәрә бәйрәме ти торғайы у, шәжәрә бәйрәме.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Шәжәрә бәйрәме.

*– Һеҙҙең шәжәрәгеҙ бар инде?*

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Безнең ясаған ие бер апа, Рәсимә апа Тайсина. Ни ҙә ясаған ие дә Ильяс абыйның, Ильясның әнейе, кем әле исеме…Зәхибә апа. Безнең туған була инде у.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Шуны табып уйлап ҡуймыйбыз.

*– Ниндәй тауҙарығыҙ бар?*

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Мынсы, беҙ мында торабыҙ, Биектау тип әйткән жир була инде бы яғы. Теге яғы Ҡарағайтау, теге яҡҡа китҫәң, Уҫаҡтау. Теге яғы, ферма ҡыры, ансы Ҡайынағас тип атала торған ие, Ҡайынағас. Анан ансы беҙнеке бу ҙур баҫыуны мындағын Зыярат баҫыу тибеҙ. Зыярат, мында беҙнеке зыярат бар инде, мында зыярат. Шишмәбез – Ҡәмәй шишмә. Ҡәмәй тип әйткән бавай булған, Ҡәмәй тигән бавай, шуныҡы кисәге дә шулый ҡалған, аныҡы булған бу шишмәнең башында буамы булған инде, буамда балыҡ та ҡараған у. Шу буамда ней ҡараған, балыҡ ҡараған инде у, Хәмәй тип әйткән бавай булған. Шуңа безнең кисәк бу Хәмәй кисәк тип атала инде, Хәмәй кисәк. Ней элек тә уланнар щаҡта беҙне «хәмәй кисәктәр, хәмәй кисәктәр» тип нират итеп бөткән булалар ие.

*– Ниндәй ағастар үҫә?*

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Мына жирек.

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Жирекләр, нейләр тал, йүкә, ҡайын, шомортлар үҫә, ыршы, ыршылар, нарат үҫә, нарат ней тауҙа күп инде, щытып щыҡты баҫыуларны басты ла.

**Мөксинова Инсиә Совет ҡыҙы:** Тағын ниндей ағащлар? Барсы ла бар инде.

*– Мунсала эшләйҙәрме?*

**Мөксинов Илдар Әүхәт улы:** Мунсала элек, буҡща элек төшөрәләр ие, хәзер төшөрмей башланылар. Элек колхоз булғанда, мунщала төшөрәләр ие, йүкә, йүкәне төшөрәләр ҙә, шушы ваҡытта төшә инде уы, шуны төшөрәләр ҙә нейгә, буамға живетәләр дә. Буамда живей инде уы бер ике ай, өщ ай ята да. Анан соң аны бер сентябрь айларда сөрәп щығарып жыйалар да, шуныҡы ҡабығын ҡырып жыйалар, ҡырып алып жыйалар да, үҙен нейгә, шундыйны ней, бер төрле навес ясыйлар, эме. Навес түгел, шундый кәртәләренә салып китәләр дә өщ аяҡка, шуңа элдереп жыйалар ие, элдереп ҡороталар да, анан соң колхоз, нейгә сдавать итәләр ие, колхозға. Аҡщасы сәйбәт щығалыр инде. Шунан мунщала, мунщала салып бөттөләр инде.

*– Был яҡта изән астар бар икән, унда ҡаптар һуккандар икән, эйеме?*

*– Нисә йыл уҡыттығыҙ мәктәптә?*

– Утыз туғыз йыл, ҡырҡҡа тутыра яздым.

*Солтанай ауылында Мәсәғутова Гөлйыһан*
*Ғәзихан ҡыҙынан (1942 йылғы) яҙып алынды*

## Сөжән ауылы

**Ғәлиева Сатира Шаймөхәмәт ҡыҙы, 1950 йылғы**

Мин меҙ туғыз йөз илленсе йылныҡы ун сигезенсе февралендә Уйын районының Толбаш ауылында туғанмын мин. Мин – Ғәлиева Сатира Шаймөхәмәт ҡызы. Но мында үскәнем мин. Әней мине алып ҡайтып киткән анан ике йәш ярымда, әтей белен килешәлмәгәннәр инде. Мине әней үзе генә ҡарап үстерде. Ҡартәнейдәр бар ие, ҡарт ҡартәней бар ий, ҡартәней бар ий, дүрт поколение йәшәдек без бер йортта. Аннары шушы ауылда кейәүгә щыҡтым инде үзебезнең, утыз алты йыл торғащ инде ана ҡый уафат булды ирем. Егерме ике йыл элек. Үзем генә йәшейм хәзер, балалар белен, балалар килеп торалар, алар эшлей әле эшне. Үзем хәзер миә житмеш дүрт йәш була. Үәт шулый йәшейем.



– Бала сағығыҙ нисек үтте? Ниндәй уйындар уйнай торғайнығыҙ бала сағығыҙҙа?

– Бала щаҡта безнеке бик шәп, яслегә йөрөргә яратмадым мин, гел ике шушы ҡартәней ҡарады мине. Гел мин уйнамаға щыҡмаға сорыйым ий, ҡартәней әйтә ие, суға барып уйнаған бул, су ташып уйнаған бул, сыйырны көткән бул, ну шундый уйыннар уйна тип әйтә ие, тормошобозноҡо теге нейләрен эшен эшләтмәгә инде.Миңке күршедә уланнар булмады. Әнә ҡый мин теге ощта, ощ яҡта миңке бер әнейнеке бер туған сеңлеләре тора ие, шул аның балалары белән уйныйбыз ие без, гел шунда барам ие алый, буйы белә жибәрмей ие ҡартәней. Баҡща утаған бул, тиеп, су ташып уйнаған бул. Былый кещкенә щаҡта уйнап үскәнне бик хәтерләмейм мин. Шулый да сигез класты бөттөм дә мин, Солтанайға йөрөп уҡып, аннары анда туғызынщы класҡа Бардаға әни жибәрде ие мине уҡымаға. Мин әнейне жәлләп, әней фермала сыйыр сауа ие, әнейне алыштырдым, сигез класны бөткәщ, ун биш йәштә. Ун биш йәштә сыйыр саумаға йөрөдөм, көнгә өщ мәртәбә сауабыз ий сыйырларны, ун биш бөртөк сыйыр бар ие группада. Әней ызбаны эшләмәгә кереште, әнейнеке уаҡыты юҡ ие колхоз эшенә йөрөмәгә, шуңа мин әнейне жәлләнем дә, уҡымый ҡайтып киттем. Фермада алты йыл бер төн алмый, бер көн ял алмый, бер көн отпуска алмый, шунда алты йыл эшләдем, сыйыр саудым. Гел алдынғы булдым, шунан эшнең ауырлығын тойдом да мин, белдем дә, уҡымаға башладым. Шушында уҡый торғащ, Бөрөжлө ауылға мынан биш километр, шу асфальт буйда тора Бөрөжлө ауыл. Шунда фермадан ҡайтам сәғәт сигездә кищке, жийәү китәм Бөрөжлөгә кищкедә, кищке уҡыуда ун бер класны бөттөм шунда, гел бишкә генә. Кищке уҡыу белән ун бер класны бөттөм сигездән соң, ун класны, ун бер түгел ий у щаҡта. Ун класны шунда бөттөм дә мине авый алып щығып китте Перимгә ун класс беле, элек паспорт бирмейләр ие бездә. Абый нищектер паспорт жүнәтте лә, алып щығып китте Перимгә эшкә. Анда Перимдә урынлаштым. Мынан миңке озаҡ сүләшкән егет бар ие. Мин аны армияға озаттым. Бер йыл сүләштек тә, армияға озаттым. Шул әйтә, ҡайт ауылға, тей. Ул армияға китте, өщ йыл хезмәт итте дә, ҡайтты да, минең янға барған, әйдә ҡайт, ҡайт,

ти, мин әйтәм, ҡайтмыйым. Шунан мында эщ әзерләп, сельсовет председательлары белен сүләшеп, мине телеграмма беле щаҡыртып алдылар, ауылға, дом культураға эшкә ҡайт тип. Ҡайттым да, районға бардым ий, районда әйтә, мин сине Сөжәнгә ҡуймыйым, Сараш ауылға ҡуям художественный руководитель итеп, тей. Шунан анда эшлей башладым, и шушынан соң сүләштек тә шушы егетем белә, торған иптәшем инде белә, ҡушылдыҡ, биш йыл йөрөшөп, сүләшеп алыштыҡ та, мына утыз алты йыл йәшәп ҡалдыҡ и уафат булды. Аннары шунан, ун класны бөтөргәщ, мин аңа барғащ, шушы тормошҡа щыҡҡащ инде, малай тыуды миңке. Малай тыуды да, алты айлыҡ булды, мин уҡымаға кердем заочно бухгалтерлыҡҡа, Кунгурға. Заочно уҡыдым да дүрт йыл, эшлей башладым счетовод булып. Аннары бухгалтер булып эшләдем. Щиткә щығып киттек, миңке уже ҡулда диплом да бар ие. Ҡазахстанда тордоҡ алты йыл, и шунда мин бухгалтер булып эшләдем. Ҡайтып киттек, әйдә ҡайтабыз, ти, ауылға, ти, ызба төзөп ҡалабыз, уланнар кещкенә щаҡта, ти. Анда барғащ, тағы берне ҡыз таптым мин. Ике ҡулда уланнар. Ҡайттыҡ та шушы ызбаны эшләдек. Щығып киткәнще дә без ызба эшләп ҡуйдыҡ ий, жуғарғы ощта, зор тоже ызба. Ҡайтҡащ, тоже шушы ызбаны төзөдөк инде. Ҡайттыҡ та Ҡазахстандан, колхоз председателе әйтә, Сөжәндә йәсле астыр, Сатира апа, ти. Бер ҡутарылған здание уы, элек мин бында счетовод булып эшләгән щаҡта уҡ у йәслене эщләделәр ие. Аны сдавать итәлмәделәр государствоға, тупсалары бийек булып ишекнеке, тупса тигез булмаға тийеш тип, ащалмадылар. Без щығып киткәщ, бер картуп базға әйләндергәндәр ий аны, йәслене, учреждениены. Ҡайттым да, шушыны, тәрәзәләрен уже аҡтарып бөтөргәннәр, ишекләре юҡ, анда кафе бар. Әле сез ҡайсы яҡтан килдегез, клубтан килдегезме сез? Клубҡа ҡаршы ие у йәсле. Шуны ащтырдым, егерменще июндә башладым эшләмәгә шушы эшне, тәрәзәләр ҡуйдырып, ишекләр, бөтөн әйберләрне дә эзләп алдым. Бөтөн эшне эшләнем дә дүртенще ноябрьдә йәслене ащтырдым. Нищә айның эщендә ошо штукатурить итеп, сырлап, түләп, анда йәслегә аз ғына кәрәкмей бит, анда бөтөн – урындыҡтырмы, постель, ҡашыяҡ, сауыт-саба – бөтөн нимә кәрәк. Ҡырҡ өщ уланнар булды шушы ауылда, йәслене ащтырдым, жигерме алты йыл эшләдем шушы йәследә заведующий булып. Районының заведующийы әйтә, безгә бухгалтер кәрәкмей, ти, ҡызларыңны уҡытып жыйдың хәзер, ти, воспитателгә, ти, хәзер ҡызларыңны ҡуям заведующий итеп, ти, әгәр уҡымаға кермәсәң, ти. Мин тағы педагогическийға уҡымаға кердем, заочно. Заочно уҡыдым, ҡырҡ биш йәштә бөттөм шуны. Аннары шунда эщләп щыҡтым ие, жегерме алты йыл. Ҡырҡ өщ йыл стажым бар. Инде хәзер пенсийәгә дә щыҡҡащ та, өщ йыл эшләдем. Сигезенще йылда туҡтадым, хәзер инде әнә ҡый нищә йыл, егерме йыллап, ащыуым да килмәсә, пенсийәдә утырам. Өйдә генә, шушы азыраҡ маллар ҡарап, у щаҡта әле, йәследән туҡтағащ, икешәрне үгезләр ҡарадым, сыйырлар ҡарадым, Нәҡип булмаса да, иптәшем булмаса да. Хәзер щибеш балалар, щибещләр, шундый нейләр генә ҡарап ҡына ултырам инде, үзем генә. Йыл сайын уланнар килә, ауылда әнә ҡый, андағы килен ул зав булып бар ие микән, ул миңке малайныҡы килен, Миңнегөл исемне анда уы. Мына шушындый тормош миңке. Ис китмәле, ҡай щаҡта искә алып, жыйып язып алам. Уланнарға истәлеккә ҡалсын тиеп. Ауылда ниндей, элек ниндей йолалар булған тип, нищек барысын да уланнарға истә ҡалсыннар, тип язып барам.

*– Ауылға, төбәккә хас ниндәй милли йолалар булған, бар, һөйләп китегеҙ әле?*

– Иске дин буйынща, диннеке үзенең айырым йоласы, культураның үзенең айырым йоласы. Культурада сабантуйлармы, яңы йыллармы – шундый бәйрәмнәр инде. Аннары тормош-көнкүрешенең йолалары, кәбен уҡытыу, кийәүгә биреү ҡызыңны, киленне төшөреү өйгә, ана ҡый шу йола барысы да. Аннары сыйырың бызауласа, уыз пирог, уыз бәрәмәще

пешерәбез инде анда жыйылышып, ыуыз бүкмә тип әйтеп сүләшәбез инде без, уыз бүкмә. Сезнеңщә яматай сүз шикелле у, безнеңщә тәмле ризык у. Һәр нимәнең үзенеке йоласы бар, ғөрөф-ғәҙәте. Диннеке тағы ҡорбан ғәйет, анда ҡорбан щалып, ҡунаҡ щаҡырып нитәсең, ураза ғәйетенең тағы үзенеке бер йоласы бар. Хәзер ҡый биш уаҡыт намаз минекеБалаларға, кемнәр килгән үтенеп, анда ҡайсы щирле килә, ҡайсы уланы сыҡтый, ҡайсы нимә ҡыла – аларны өшкөрөп ҡайтарасын. Шундыйыраҡ йолалар әнә ҡый, ҡартайғащ.

*– Өшкөрәһегеҙме?*

– Әә, Аллаға шөкөр, барысын да эшлейем. Уҡып, теләкләр теләп, күрше-тирәләрне, нимә эшлей барысы да. Сатирә апа, бөгөн пещәнгә башлыйбыз, Сатирә апа, бөгөн уборкаға төшәбез, тип киләләр, әнә ҡый. Аларға уҡыйым, ә әле внучкам хәзер генә Чайковскийға икенще курсны бөтөп ҡайтты, имәнещ ҡаты, фельдшерлыҡҡа уҡый, ҡартәней, миңә уҡы, мин бөгөн экзаменға керәм, ти. Шулый, кем нимә сорый, шуны эшләп ятам. Әнә ҡый бер-ике йыл клубҡа йөрөмейем бик, элек клубта да йөрөдөм, бөтөн нейләрне алып пардым мин. Анда әйверләр тектереп, костюмнар – барын да мин тектердем, костюмнарын да клубныҡын. Быларда әнә ҡый бөтөн мероприятиеларда ҡатнашып, бөтөн нейдә жөрөгәннәрнең кейем анда, сабантуйларда ана ҡый, бу кейемнәрне барын да мин тектереп жыйдым. Администрацияда булса, администрация, ана ҡый бу кейемнәрне барын да мин тектердем, әнә быларны, ирләрнекен дә. Менә бу суҡыр малайы минең күршедә тора ие, мулла, үлде инде, баянда уйный ие, ааай, матур уйный ие, жаңы жыр өйрәнеп тә алам, кереп китәм шунда, күршедә генә тора ие. Безнеке Сөжәннеке ике йөз йыллығы булды да ана ҡый, анда безнең зат карточкаға төшөп жыйдыҡ барыбыз да, менә ана уланнары, туғаннар, Балтаевлар барысы. Мынсы администрацияда, мин дә ана ҡый, Старый Шинь тигән ней ащтылар ий. Ун бишенще йыл. Ҡайда әле ҡый, кейемнәре дә төшкән бар ие ҡый. Башҡортостанныҡы ана ҡый әллә нищә грамота бар минеке. Дипломнар, жыр буйынща да, фольклор буйынща да күп жөрөдөм мин.

*– Ауылығыҙҙа ғына йырланған йырҙар, таҡмаҡтар бармы?*

– Элекке мөнәжәтләр бар инде. Элекке мөнәжәт, ҡартәнейнеке мөнәжәте бар ие. Мында щамасыз язған нимәм миңке. Ә мына Башҡортостанныҡы рәхмәт хаты.

Бу «Шахта» көйө ҡый, бик безнең ауыл яратып жырлый инде:

Китә ҡазлар, китә ҡазлар,
Китә ҡазлар Донбасҡа, шул.
Мин дә уйлап торам әле
Шул ҡазлардан ҡалмасҡа.

Әле ней ащылмаған ҡый әле, тауыш ащылмаған. «Кил син тәүбәгә» тигән Ильяс Халиҡовныҡы мөнәжәте беле күп йөрөдөм, Пермнәргә бардым нищә мәртәбә, смотрларда, тыңлыйсызмы?

Уза ғөмерләр, ащыла киңлекләр,
Гөнаһларың тәүбә, тәүбә көтәләр.
Күңелләр сыҡрый хаталарға,
Әжәлең килгәнще кил син тәүбәгә.
Нәф(е)сең әйтә, синең уаҡытың күп, ди,
Бер кем ҡулында да ышаныс юҡ, ди.
Уаллаһи-билләһи, хисабың зурдыр,
Соң сулыш килгәнще тәүбәгә кил әйдә.
Ҡәлепне уята Ҡөръән дәлил белән,

Иманлы ғәмәлләр жәннәткә илтә.
Уян син, уян, ғәфләт йоҡосонан.
Ҡәбереӊ ащылғанщы кил син тәүбәгә.
Нәф(е)сеӊ әйтә, синеӊ уаҡытыӊ күп, ди,
Бер кем ҡулында да ышаныс юҡ, ди.
Уаллаһи-билләһи, хисабыӊ зурдыр,
Соӊ сулыш килгәнще тәүбәгә кил әйдә.
Йөрәк тибешеӊне тыӊла, нейләр әйтә,
Дөрөс йәшәргә, дип, Раббым безгә әйтә.
Гөнаһнарыӊны барла, ярлыҡау син сора.
Тәннән жән киткәнще тәүбәгә кил әйдә.
Нәф(е)сеӊ әйтә, синеӊ уаҡытыӊ күп, ди,
Бер кем ҡулында да ышаныс юҡ, ди
Уаллаһи-билләһи, хисабыӊ зурдыр,
Соӊ сулыш килгәнще тәүбәгә кил әйдә.
Аллаһныӊ рәхмәте киӊ, жаннарныӊ асылы,
Күкләр күкрәүе дә ҡабатлый аны,
Гөнаһлы ғәфләтнеӊ ярасы сауыҡсын,
Жәһәннәмгә юлыҡҡанщы кил син тәүбәгә.
Нәф(е)сеӊ әйтә, синеӊ уаҡытыӊ күп, ди,
Бер кем ҡулында да ышаныс юҡ, ди.
Уаллаһи-билләһи, хисабыӊ зурдыр,
Соӊ сулыш килгәнще тәүбәгә кил әйдә.
Соӊ сулыш килгәнще кил син тәүбәгә. Амин.

Миӊке хәзер шундый инде, жырға бик шәп ней бирмейем, шушы мөнәжәтләр белән, ҡартәнейләрнекен ҡабатлап, ултырам инде шунда, шушылый, көннәр үтә.

*– Ҡәлеп нимә була ул?*

– Ҡәлеп – йөрәк, ҡәлепне уята, йөрәкне уята, аӊны уята, зиһенне уята. Ҡәлеп тип шушы уҡыуда ҡулланам мин аны, үземнеке аятләрне уҡығанда, зекер-тәсфихләрне уҡығанда, ул сүзләр гел ҡабатлана безнеке ул, ғәрәп сүзләргә керә.

*– Ауылға бәйле легендалар бармы?*

– Легендалар күп у. Безнеӊ шушы ауылда Хәбибулла Ишан –легенда ул. Аныӊ шушында мәщетнеке нейендә бар у, язылған әйвәт итеп, әйвәт итеп язылған әйверләр күп. Ҡәбер ташы ҡуйды анда ҡый щитән ҡуйған щаҡта әнә ҡый. Хәбибулла Ишанны безгә Пермьдән исторический кафедрадан Гөлсинә исемле ҡыз килеп аны безгә аӊлатып, шунан эзлей башладыҡ без аны Хәбибулла Ишанны кем икәнен, оказывается, ул безнеӊ ауылдан бер Фазылжан исемле бабай нейгә барған, хажға барған. Алты йыл йөрөгән. Щығып киткән өйөнән бәхилләшеп, ҡайталмасам, саубулыӊ, хажға киттем, тип. Хажға барғащ, әйткәннәр мыӊа. Бер меӊ сигез йөзенще йыллар булған. Барғащ әйткәннәр, шул ҡәдәр жыраҡ ердән нимәгә килдеӊ ауылығызда ишан күмелгән, тип. Ишан – у пиғәмбәрләрдән кищерәк булмаға тейеш ул ишан тигән сүз. Әйткәннәр, ауылығызда ишан күмелгән, исемен үзегез беләсез, аныӊ нуры жирдән күккә ашҡан, ҡәбернеӊ өстөнән була инде. Сез аны күрмисез, мин аны күреп торам тигән. Ауылығызда хаж ҡылыр урын сезнеке Сөжәндә, тип әйткән и ҡайтып киткәщ, щитәннәр ҡорған у үзенщә, шушы Хәбибулла ишанға и аны гел, мике лә күз алда әле нищә төрлө итеп ниттеләр, щитәне жемерелде ие, шушы Гөлсинә килеп

историческийныҡы, доцент килеп, безне уятып ҡый шулай, ащтыҡ без аны миғраж кищәсе көнөндә, ике мең ун өщтәме шу шунда...

Тағын да зыяратта мәщеттә минеке ҡартәтей эшләгән указной мулла булып, әле бер көннө генә ҡарадым, аңа 85 йыл атылыуына, аны алып китеп утыз етенще йылны атҡаннар, Свердловскиҙа ҡырда ҡәбере, әле яңыраҡ ҡына бардым язғыда, майның ахырында, Свердловскиға кергән жирдә шунда ҡәбере, соңыдан эзләп таптыҡ без аны, бында мәщеттә мулла булып эшләгән, атылыуына 85 йыллыҡҡа ҡорбанлыҡ щалдырдым да мин, ун жите бөртөк ҡалғаныбыз внуклары, оноҡлары, шуларны жыйып, кафела ҡунаҡ ясадым. Үзебезнең ҡартәтей дә легенда безнеке, әнә ҡый аңа мемориальный доска ащтырдым мин мәщеттә. Мәщетнең алдында фотосы бар аның, ҡайсы төштәдер. Мәщетебез безнеке бик почетлы алый, дин буйынща да бөтә даталарны да үткәреп барабыз.

Болгар жеренә бардым әнә ҡый, нищәнще йылны йөрөтөп апҡайттылар, мында әйвәт эшләгәннәр, тиеп, бүләккә бирделәр ий путевка. Шу жылны мәщет ащтылар, Аҡ мәщет анда, Болгар жирендә, мин барған жылны.

Мәщетнеке манараны кемнәр кисеп төшөргән, аларны жыйыштырып жыйдым мин, утыз етенще йыл ҡартәтейне алып киткәщ, ауылныҡы әнә ҡый теге сатлыҡ йаннары. И Шишмә тауда әнә, минеке аяҡ ащта ғына ике ҡыз, исемнәре берсе Зөлхижә, берсе – Мөкәрәмә исемне ҡызлар хәйер өстәп килеп щыҡҡаннар, нейдә, ун житенще йылларда, нейдә, Гражданнар суғышы уаҡытта, Ҡазан яҡтанмы, Уфа яҡтанмы килгәннәр уы ике ҡызыҡайлар, эшще ҡызлар булғаннар, шулар үлгәщ, мында тауға апменеп жыйғаннар мында аяҡ ащҡа.

*– Хәйер өстәп хәйер теләп буламы?*

– Ээ, хәйер теләп була, инде хәйер өстәп өүдән-өүгә йөрөгәннәр. Шулар ана ащларынан үлгәщ, тауға апменеп жыйыштырғаннар. Ансы бер ней, аларға да уҡыйым инде гел. Мында ун өщөнщө йылда Сөжән ауылы жана, бу ауыл жанып бөтә, ун өщөнщө йылда. Бер Вәлиев Ғәфиәт бавайныҡы, ул бавай әлерәк кенә үлде, әнейе шунда игезәк улан тапҡан да, улан тапҡан да мунща яғып евәргән. Элек түвәләр салам түвәле булған барыбер, шул түвәгә ут ҡапҡан жәйгедә, анан бөтөн ауыл жанған.

*Сөжән ауылында Ғәлиева Сатирә*
*Шаймөхәмәт ҡыҙынан (1950 йылғы) яҙып алынды*

**Мансурова Гөлсирә Миңнеғәлим ҡыҙы, 1952 йылғы**

Мансурова Гөлсирә Миңнегәлим ҡыҙы булам. Мең туғыз йөз илле икенче йылның ун бишенче сентябрендә тудым. Сөжән ауылында тудым, шунда йәшәдем, ғүмер буйы шунда йәшәдек. Без дүртенче класҡа ҡәдәр ауылда укынык, анан соң Султанай сигез йыллык мәктәбен бөтөрдек. Аннан соң Сараш мәктәбендә укыдым. Аннан соң нейгә, пешекще һөнәрен үзләштердем Пермь шәһәрендә, алты ай. Анан соң һәр бер кеше, йәшләр – бары да фермала эшләделәр, сыйыр сауалар. Анда сыйыр сауыущы булып та эшләдем.




Дүрт йыл, биш йыл. Аннан соң Росгосстрахҡа кердем. Анда күп эшләдем инде, ун дүрт йыл эшләдем. Аннан соң инде, шу ауырыуым сәбәпле, щығып китергә мәжбүр булдым, но эщлейсе килә. Эщләмей сыдый алмыйым. Аннан соң өүдә генә утырырмын, маллар ҡарап, рәхәтләнеп йәшәрмен тип уйланым, булмады. Бер йылмы ултырдыммы, юҡмы, нищектер язасы килә, гел эщләсе килә.Үземнең ауылға кердем инде клубҡа, житәкще булып, директор булып инде. Анда эшләдем бер йыл. Аннан соң щығыйыммы тип заявление яздым, тағын бер йыл эшләдем, ике йыл эшләдем. Аннан соң, ауырыу сәбәпле генә, бардым больницаға инде, анда тикшерделәр, башым ауырта тип кенә бардым. Өлкәгә жибәрделәр инде. Аннан соң бик ҡаты ауырыу таптылар, күземдә инде. Аннан соң инде мин аны йәшердем, кешегә әйтмәдем. Шул көннө үк группаға щығардылар. Мин ул щағы утыз жите йәш ием. Ну тормошно көттөк. Ирем белән тордок инде ҡырыҡ йыл. Әйбәт булды, колхозда эшләде ун йыл, анан соң буровойда эшләде. Ике ҡызларым бар. Шулар белән донъя – тормош көттөк инде. Үзебезщә үзебезгә айырым йорт эщләп щыктыҡ. Хәзер, ҡызлар, Аллаға шөкөр, ҡызларым ауылны бик шәп яраталар. Үзләре ҡайтып, хәзер йорт төзейләр алар да. Ҡызларымның ҡызлары да ауылны яратып, рәхәтләнеп ауылда йәшейбез, әлхәмдүлилләһ, шөкөр.

*–Ауылығыҙҙың тарихы буйынса нимәләрҙер һөйләй алаһығыҙмы беҙгә? Атамаһы ҡайҙан барлыкҡа килгән?*

– Аны безгә нищектер әтейләр генә сөйләнеләр инде. Был матур нейгә балыҡщылар балыҡ тотоп килеп щыҡҡандар инде. Безнең Нөнө йылғасы булған инде, Тол йылғадан соң, Тол йылғасының ҡушылдығы тип әйтәләр инде аны. Мында йорт та, бер нәрсә дә булмаған. Аннан соң, берсе балыҡны ҡармаҡ белән тотҡан тип, көлөп сөйлейләр инде, ә икенщесе инде сөзөп барған инде. Барған да икесе туҡтағаннар, инде осращҡаннар. Юҡ, син балыҡ ҡая, нищек ҡаптырдың былый. Юҡ, мин ҡаптырдым, шуңа эре балыҡлар тип әйткән индее. Ә икенщесе: юҡ, син быны ҡаптырмағанын, сөзгән ул, сөзгән, юҡны сөйлей, ти. Шулый Сөзгән, аннан соң Сөжән, шунан килеп щыҡҡандыр әле тибез. Шунда йоҡларға ҡалғаннар әле, тип әйтеп сөйлейләр ие кещкенә щаҡта, әтейем шулый сөйлей ие. Шундый ҡызыҡ булып, шунда улар йоҡлап ҡалғаннар, аннары йорт төзөгәннәр. Бик матур булған тәбиғәте. Безнең Сөжән бик матур тәбиғәт, районда иң беренщедер, тип әйтәсе килә, ис китәрлек.

Сабантуйлар шундый матур үтә, Нөнө йылғалары, менә шу йылғаларда су ҡойонып, рәхәтләнеп бергә-бергә йәшәп үстек инде. Йәштәшләрем, иптәшләрем күп булды, туғаннар, тумащалар. Хәзер ҙә әлхәмдүлилләһ, шөкөр, әйбәтләр. Безнең хәзер дә Мөбәрәк иген үстерә күп иттереп, беренче урыннар ала районнарда, аның малайы ла шунда эшлей инде. Үкереп тора колхоз, ҡырлар инде, игеннәр үсеп утыра. Мында мал да күп ҡарыйлар, тоталар инде. Сыйырлар да бар. Әлеге көндә лә ауыл шаулып йәшей, тип әйтәсе килә. Бик кеше булдыҡлы, эшщән, тырыш, барсы да әйбәт. Иң әйбәте – кеше бердәм бездә. Безнең хәзер мәщетебез, мәщетебезнең инде жигерме ел былды төзөлөүенә, бер ҡащан да мәщетебез ябыҡ торған юҡ. Кеше дә күп йөрөй. Йәшләр дә менә Аллаға шөкөр. Күрше безнең ауылдан, Бөрөжлө ауылынан Таһиржан эшлей инде бездә, безнең хәҙрәт булып инде. Барысы мында, ниндей эш была, бер-берсенә бердәмләшеп, йәрдәмләшеп йәшейләр инде. Бер-берсе өщөн янып торалар. Кемдедер турында нищектер язасы килә алар турында, обязательно һәр бер кеше турында мин язып ҡуясы килә, хәтердә ҡалсын, тип. Менә шундый яҡшы кешеләр йәшей, әлхәмдүллиләһ. Бер ҡащан да кешегә ҡаты сүз әйткәннәрен дә ишеткәнем булмады, шуңа хәтле, ниндей генә булсам да. Бик әйбәт ауылыбыз, ис китәрлек.

*– Тауҙарҙың, йылғаларҙың атамаларын әйтеп китһәгеҙ, һәйбәт булыр ине.*

– Безнең йылға Нөнө, безнең сыу ҡойона торған йылғаларыбыз. Аннан соң безнең бы яҡта былған инде Алтын кәмә тауыбыз бар, әме. Безнең Алтын кәмә нищектер электән, боронғодан, кемдер инде кәмә тип әйтә, көймә, тип тә әйтәләр инде. Кәмә тип әйтәләр инде көймәне, лодка русща тип әйтәләр аны, шунда алтын күмеп калдырганнар, шуны эзләгәннәр, эзләгәннәр, тапмағаннар, тип әйтәләр инде. Анда зур-зур, биик-биик таулар. Аннан соң мынсы инде безнең Шишмә-тау, Шишмә-тау тип әйтәләр. Аны Уйын-тау тип тә әйтәләр. Шишмә тауын элек Уйын-тау тип тә әйткәннәр. Безнең әнейләр, әтейләр йәш щаҡларында шунда Уйын тауда тағаннар ясап, кищке уйын шунда булған. Анда гел шунда уйнағаннар. Анан Боланға төштөләр инде соңонан. Тағаннар тағынып, ошо кищке уйында гел шу Уйын-тауда булғаннар инде, Уйын-тау, Шишмә-тау, Алтын кәмә-тау. Ә бездә шишмәләр дә күп. Беззең те яҡта беззең үзебеззең Салкын шишмә тип әйтәбез инде. Ә бы якта безнең Ауыл шишмәсе. Ауыл шишмәне хәзер дә ҡарап, саҡлап торалар. Сатира апабыз бар бездә, барысын да, зыяратларны ҡарап, тәртиптә тоталар. Шундый әйбәт кешеләр бар беззә, ис китәрлек. Мәщетләребезне әйтеп торам да. Тирә күрше ауыллардан әллә ҡайда беренседер, тип әйтәсе килә. Бөтөнөсө әйбәт, бөтөнөсө яҡшы күңелле кешеләр, бердәм шундый, бер-берсе өщөн үлеп торалар бездә халыҡ. Шул хәтле әйбәт, шул хәтле әйбәт. Күрщеләр безнең шул хәтлем татыу барсы белән дә. Барсы да үзебезнең туғаннар шикелле, әлхәмдүллиләһ.

*– Йылғаның исемен Нөнө тип әйттегеҙ. Нимәнән килгән ул исем?*

– Ансын белмейм, ниңә Нөнө былғандыр у. Без инде кещкенә тирән Нөнө, тип әйтәләр ие инде, без тирәнендә түгел, бу Нөнөдә суға төштөк инде. Ә сабантуй хәзер шунда была. Анда нейләр ҡуйғанлар инде, нимә тип әйтәләр әле, ҡыйыҡ бағана, тип, шунда барадыр инде, әме, былый тирбәлеп тора у, тирбәнеп тора. Если бара алсаң, ощона ҡәдәр инде, молодец буласың, килеп әйләнәлсәң. Безнең ауылда ғына шундый инде у. Ә инде барып нейтә алмасаң, суға щумалар да рәхәтләнеп шунда йөзәләр, ҡызыҡ шундый, менәләр, барып төшәләр, шундый ҡызыҡ, ис киткещ була беззә сабантуйлар һәр йылны, әйвәт. Халыҡ бердәм шундый, талантлы, тип әйтәсе килә, таныҡлы кешеләр күп бездә. Йәшләр дә инде дингә тартылалар бик шәп. Ансы тоже да сүйенеш, тип әйтәм мин. Бар да укыйлар. Ә безнең кийәү дә уҡый, Аллаға шөкөр, азан әйтә. Аллаға шөкөр, аллаға шөкөр. Шушы хәлдә йәшәсәк, бик яҡшы булған булыр ие.

*– Ауылга гына хас йырҙар, таҡмаҡтар бармы?*

– Безнең ауылға бағышланған “Сөжәнем” тип аталған шиғырға жыр яздылар, ауылыбызның гимны тип әйтәләр аны, бөтөн бәйрәмнәрне, сабантуйларны күтәреп ауылныҡын, шушы гимн белән башлыйлар. Аны Мөбәрәкнең малайы жырлый матур итеп, бик матур итеп жырлый аны, сабантуйлар шуның белән башланып китә.

*– Һеҙҙең ауылға гына хас йолалар, традициялар бармы?*

– Искә төшәр әле соңодан, бардыр инде анысы. Безнең ауылға ике йөз булды, тау башта күргәнсездер әле анда, “Сөжән – мең сигез йөз ун жиде” тип язылған, ике йөз йыллығы үтте. Ә безгә хас шишмә бар инде. Сатирә апа нитте ҡый, әме, шул шишмәне, ауыл шишмәне тотоп алып аны, бөтөн хәзер почти район тип әйтерлек шушында шишмәгә суға килә безгә. Бер кемдә дә булмаған ишан хәзрәтнеке ҡәбере бар бездә. Шулый әйтәләр: Мәккә шәһәренә барғанда, шушынан кемдер киткән Мәккәгә, Мәккә шәһәренә киткәндә, шунда шул кешегә әйткәннәр: “Син нәмәгә килдең мында? Сезнең ауылығызда үзегездә мәккә кебек нур балҡып тора, нур һауаға бөркөлөп тора”, – тип. Шушы ишан хәзрәтнең ҡәберенән һауаға нур балҡып тора, тип әйтәләр. Аңа бик әйвәт итеп щитәннәр ҡуйып, аны матурлап ҡуйдылар. Кищкедә кем щыҡса да, анан шулый ҡарасалар, анан нейтеп, шунан ут щығып тора икә. Гел шулый булған. Аны дәже безнең әтейләр дә күргәннәр, кищкедә щыҡтылар исә, гел шунда, шунда безнең зыярат ҡырда, шушы яҡта, мәщет ҡырда, әме, мәщеттән ераҡ түгел. Хәбибулла ишан хәзрәт.

*– Киленгә көйәнтәләп шишмәгә алып барыу, һыу юлы күрһәтеү йолаһы юҡмы?*

– Андыйлар булща юҡ, но үлем-фәлән булғанда инде, нитәләр инде, именно шу шишмәләрдән алып, теләкләр теләп, у йола бер ҡащан да бөткәне юҡ, соңғы юлға озатҡанда инде кешене. Тәрбиәләп, иртән үк тороп, шул шишмәләрдән су алып киләләр.

*– Милли аш-һыуҙар бешерәһегеҙме?*

– Ой, аш-сулар пешерергә бик шәп яратабыз инде, бигерәк тә шәңгә, ҡыстыбый, татар ашларын. Күпщелек шуны ашыйбыз инде. Бик шәп яратабыз шу нейләрне. Мищтә пешерәбез бәлеш, төрлө-төрлө бәлешләр, татар ашлары инде. Аннан соң, элеккеләр безнең щөгөндөрөк ҡуас, тип әйткәннәр инде. Щөгөндөрне пешереп, аннан соң нейләр саласың да инде, элек нимә тип әйтәләр әле, икмәкне күпермәгә салып, ащытҡы, ащытҡы тип әйтәләр инде аны, икмәк ащытҡы белән щөгөндөрнө салып. Дрожжи белән ащытҡы ясыйбыз ҡый, ҡайнап тора, ти инде, ҡый, күвә, ти, дрожжи белән, ана шул ащытҡы тип атала бездә. Ә икмәкне тоже бездә шушындый ащыткы белән ащыталар. Даже дрожжи салмыйлар. Суға он салып бер аз ниткәщ, бер аззан үзенән-үзе ащый у, вот шу ащытҡы у, дрожжи да салмыйсың. Ә куасны беләсез инде, анысын аңлыйсыз, только бу солодтан ясалған куас булмый, щөгөндөрдән ясалған була, куас щөгөндөр куасы тип атала. Аны урысща квас тип әйтәләр инде, без куас тип. Щәк-щәк пешерәбез, щәк-щәк баллыйбыз, щәк-щәк бар, ди у аны, жоҡа тип әйтәбез, щәк-щәкнең зорырағын инде, әме. Уны тоже үзебез пешерәбез инде пищ алда. Яфраҡ бәйлейбез инде жәйгедә, яфраҡ бәйлейбез, яфраҡҡа обязательно мәтрүшкә ҡушабыз, щирикей тип әйтәбез аны, щирикей үлән, мәтрүшкә була инде.

*– Пикан тип күп ишеттек, тик уны ныҡлап аңлатҡан кеше булманы. Нимә ул? Русса* нисек була?

– Әнә мин аны белмейм. аны столовыйда ла сорыйлар аны, нищек атала у пикан русща, тип, аны бер кем дә белмей. Пиканнан шәңгә пешерәбез. Иң беренще пикан шәңгә, пиканнан пешерәсең... Бәрәңгене кәртүк тибез без, ҡайсы картук тип жибәрәбез, картук беттеме, картугың бармы әле, тип. Потолокны путулук тибез, түшәм тип әйткәнебез юҡ, түвә тип тә

әйтмейбез, путулук, стена, тәрәзә, идән, палас, яңғыр тип әйтмейбез, яуын, тибез. Ағащлар шулай уҡтыр инде, шоморыт, тип әйтәбез, шоморт тип әйтмәйбез, шоморыт. Ҡарағат, тибез ҡарлығанны. Шартлама бармы сездә? Желәк, тик эресе, ҡызылы ҡайын жиләк түгел, аны бездә шартлама, тейләр. Аны жир жиләк, тип әйтәләр микән, белмейем. Әдәбищәсе жир жиләк була микән, шулый буладыр, шартлама, тип әйтәбез инде без аны, өзгәндә, шарт-шарт-шарт тип өзөлә бит, шартлап жыйыла. Өмөжө – малина. Щалғы тибез, тырнауыщ – тырма, пещен жыя торған, ишек алдын ишек ал тип әйтәләр инде. Рубашка рубашка тип әйтәбез, ир күлмәк, хатын-ҡыз күлмәк, хатын-ҡызларныҡын күлмәк, тип әйтәбез, ә ирләрнекен рубашка, тип әйтәбез. Сөйләш, тип әйтмейбез, сүләш, тибез, сүләшәсеңме, тип, тип, тип тигәнне тип әйтәбез сүз сайын. Ҡыйны ебәрәбез инде аны, бардым ҡый, сездә бит тейләр.

*– Берәй шиғырығыҙҙы уҡып күрһәтегеҙ әле.*

– Офоҡларда ҡалса ҡызыллыҡ,
Үкенещкә түгел, йәшей алсаҡ,
Узған ғүмерләрне,
Мизгелләрен истә ҡалдырып.
Йөрәгегез әгәр саф булмаса,
Сез ҡызларға щәщәк итмәгез.
Матур сүзләр сөйләп, ә соңынан
Көлөп кенә үтеп китмәгез.
Ҡызлар күңеле умырзая кебек.
Шундый керсез була үскәндә.
Уйла, егет, син хаҡлымы аның
Йәшлек сабағынан өзәргә?
Ник шулай да сез, егетләр,
Аңламыйсыз ҡызлар йөрәген?
Болоннардан сезгә щәщәкләрдең
Иң матурын сайлап йөргәнен.
Шушы щәщәк белән теләгән
Аңлатырға йөрәк серләрен.
Һәм жырларга сезнең белән үткән
Тормоштоң тәүге эзләрен.
Ал щәщәкләр үщсә юлығызда,
Таптау түгел, уйнап өзмәгез,
Сез, егетләр, шаяргандай булып
Йәшлек хисләренән көлмәгез.
Ҡызлар күңеле умырзая кебек –
Шундый керсез була үскәндә.
Уйла, егет, син хаклымы аның
Йәшлек сабағынан өзгәндә?

*Сөжән ауылында Мансурова Гөлсирә*
*Миңнегәлим ҡыҙынан (1952 йылғы) яҙып алынды*

**Уразова Гөлсирә Мәғрүф ҡызы, 1952 йылғы**



Мин документ буйынца Уразова Гөлсирә Мағруф ҡызы, мин ике исемле, әней мине, кещкенә, яңы тыуғащ, Гөлфизә тип атаҡан, үзенеке дустыныҡы ҡызы да Гөлфизә, мине дә Гөлфизә тип атаҡан, шунан мике исемне әтей документ алырға, элек Батырбай ауылында ие сельсовет, шунда барып, исемне онотоп киткән, нигә язып алмағандыр инде азыраҡ,барған да эй, онотоп киттем ҡый инде, ҡызлар, Гөл керә ие башында, Гөл керә ие исеме тип әйткәщ, тәки исемне исенә төшөрә алмаған, Гөлсирә тип язып ҡайтарғаннар. Но барыбер мулла нисек ҡушҡан, мине Гөлфизә тип әйттеләр, ә мәктәптә – Гөлсирә тип. Ике исем, күп кеше белмәй минеке ике исем икәнне. Фамилиям – Уразова, иремнеке фамилия, ә элеккесе – Галиева ие. Отчество тоже аны документны Магруфовна ие мин, аны соңыдан паспорт алғанда, ялғыш Маграфовна, тип бирделәр, хәзер Маграфовна. Маграфовна, тип бирделәр соңыдан паспортны. Без как раз щиткә щығырға торабыз ие, яңы паспортлар алып, ашығып, аны төзәтеп тормадылар.

Мин мең туғыз йөз илле икенще йылның икенще июнендә туғанмын, икенще июнь, әней әйтә торғанейе, жыен числала тудың, тип, жыен шул июнь айда була бит, сабантуйлар. Ҡыр эшләре бөткәщ, гел июндә шундый сабантуйлар.

Без биш бала, алты бала бер семьяда, бына әле бер сеңелем ҡалды, малайлар, авзый, энекәйләр үлеп бөттөләр, әле сеңелем бында Пермдән килде лә, бында, нейдә әле ул, бездә, нейгә генә щығып китте әле, массажға менеп китте әле юғары, ҡайтып житәр әле.

Биш бала тыудыҡ, кещкенәдә у уаҡытта нимә, суғыштан соңғы нейләр инде без, әней белән әтей соғыштан соң табышҡаннар, ҡауышҡаннар, авыйым ҡырҡ сигезенще йылныҡы, мин илле ике, кещкенә энекәйләр тағы өщәү, сеңлем ана ҡый илле алтынщы йылныҡы. Суғыштан соң инде ащыраҡ ваҡыт инде у, уҡығанда тоже ащлы-туҡлыраҡ ие инде у, башта Сөжән башланғыщ мәктәбендә уҡыдым дүрт класс, анан соң Батырбайға бардыҡ, Батырбайда ие мәктәп, анда интернатта тордок ҡышын, язын-көзөн жейәү жөрөп уҡыдыҡ. Элекке уаҡытта нимә, ялға ҡайтсаҡ, эш өйдә, элекке уаҡытта бездә ҡап суғып, шуның беле үлмей ҡалғаннардыр инде, үлмей ҡалғанбыздыр, тием, барыбыз да, йорт сайын анда бишәр, сигезәр, унар уланнар ие, без юғары ощтан, хәзер бында түбән ощта кийеүдә. Ялға ҡайтҡанда ҡап суктырып, шу ҡапларны сатып, магазинда үтәләрейе, сдавать итеп, аҡща табығы ни, шуға азыҡ алып. Мал ҡарыйларейе әнейләр, мал ҡарыйлар, жәйдә пещән эше, бәрәңге утыртабыз, жиләк-емеш йыябыз, сауытлар тоттороп, безне әней, шартлама инде у безеңщә, еләккә, шартламаға щығарып ебәрәәйе яланға, жыйып ҡайтабыз. Язын ҡаз бәпкәләр, өйдә ултырталарейе элек ҡазларны, ҡазларны өйдә утыртып, щығарып-керетеп, ҡаз бәпкәләре өйдә щығып, шуларны әней безгә ҡуша ҡарап тормаға инде, ҡарға-фәлән алып китмәсен, тип.

Мин күберәге, миән соң тағы өщ энекәй, бер сеңлекәш тыуғащ, гел мин сәлей төптә сәлей тирвәтеп утырдым инде, шуларны ҡарап, кещкенә генә көйө күтәреп йөрөтөп, әней үземнеке жигәрле ие у, бөтөн эшләрне үзе эшләде, күп эшләргә әле, кейәүгә дә әле щығып киттем мин, белмейем дә ие. Шуларны ҡарап үстереп, шуларны, гел сәлей төптә, житешкәндә, щығып уйнап алабыз ие шунда. Әнейләр үзләре әле алар ҡырда эштә, кищ кенә

ҡайталар, өйдә идән себереп, ҡашыяҡ жыуып, шу энекәйләрне ҡарап утырам инде. Мәктәп йылларында, мәктәпләрдә уҡығанда тоже язғыда-фәләндә, колхоз щығара иеме икә, шу безне иген утарға щығарып жибәрәләрей, иген утыйбыз шунда, аннары ял иткәндә, ҡулда бәкеләр булғас инде, ҡайынны нитеп, тузын телеп, щөщөк ашыйбызей, бик тәмне ие шу щаҡта, хәзер дә бардырмы инде, жуҡтырмы, аңа ис китмей инде хәзер. Ҡайын щөщөк – ҡайын сыуы була башта, азаҡ ҡайын сыуынан соң, көннәр жылынғащ, шу сыу щөщөк тип атала у, щөщөк, нимәсе була икә у, сеззеңщә, әдәбищә нимә икә әле у. Ҡуйырған ҡайын сыуы буладыр инде у, баллы была ие. Хәзер дә бардыр инде у, хәзер инде анда кем нитсен инде, урманға йөрөп ни. Хәзер инде ҡороп бөткәндер у, жәйгедә, эсседә ҡороп бетә. Әнә шуларны ашап, уйнап, бик күңелле үстек инде, үзебез ул щаҡта инде ащлы-туклыраҡ булсаҡ та, шуңа хәзер жырлап ебәрәм ҡый:

Без йәш щаҡта болоннарда
Сикреп мендек атларға.
Сикреп мендек,
Сикреп төштөк,

Сер бирмәдек ятларға, – тип. Ащлы-туҡлы булсаҡ та, бик күңелле йәшәдек. Хәзерге нейләрне ҡарап, эщләр сызлый инде. Күп уйыннар уйныйбызый, төрлө уйыннар, төрлө-төрлө, лаптылар анда, ҡащыш уйыннары, йөгөртөү уйын тигән уйыннар уйнау, күп уйыннар уйныйбызый. И лапта суғып, и тегесе, городки, ҡый. Шундый уйыннар уйныйбызый. Кещерәк щаҡта, “класс” тип былайына сызып сикереп уйныйбызый, теге нейләр ташлап, уатылған, щоҡор уатыҡлардырмы нитеп, шундый уйыннар да күп уйныйбызыйы, бау сикереп, бик шәп итеп уйныйбызый. Хәзерге уланнар ниткәдем юҡ, унда, юғарғы ощта таулар шоп-шома була ие каникулларда, анда таулар бит, анда щана белән жыйлып алғащ, щаңғы белән, былай менеп, тап-таҡыр итәбезей, ике аралардан шыуып уйныйбызый, тап-таҡыр була ие, хәзер бала-щаға күрмәссең, азайдылар, азайдылар. Безнең элек ауыл зур ий, бөтөн яҡларда кеше тора ий, щығарып жибәрмейләр ий колхоздан да, документ та бирмейләр ий, уҡып беткәщ, сразу щығып китәләр, тип. Мин ун класс бөткәщ, фермада, колхозда эшләп алдым, анан нищектер шунда паспорт жүнәтеп, нищектер сөйләштереп, аннары ғына щығып китәлдем, сразу ғына уҡырға да кереп булмады инде, ащлы-туҡлы тигәндәй, уланнар күп, эшләмәгә кәрәк, аҡща кәрәк. Пермдә ике йыл эшләдем дә, әнә, ҡый, кейәүгә щығып ҡуйдым, уҡымадым, кейәүгә барғащ, уҡырмын әле, тип жөрөдөм әй. Ҡәйнә ҡарщыҡлар: “Ана, уҡысың килгәщ, кейәүгә бармыйлар”, – тиделәр. Колхозда эшләдем дә, анан соң, әнә, щиткә щығып, тимер юлда эшләдек.

*– Ҡәйнә ҡарщыҡлар тигәйнегеҙ?*

– Минеке иремнеке әнейе дә бар ие, ҡартәнейе дә бар ие, алар иске йолалар беле, ней, барыбер, хәзерге кебек түгел инде, без киленнәргә андый ней түгелбез хәзер, без киленнәргә үзебез килен хәзер, улар ялан аяҡ та йөрөтмейләр ий, ялан баш та йөрөтмейләр ий, эшкә белмәгә кәрәк. Эшкә белмәй торсаң, нейтәләр инде барыбер, ҡағалар-суғалар, “эшләргә белмәгәщ, ниңә соң кейәүгә щыҡтың соң”, – тип. Эшкә белмейбезме әллә, уҡып ҡына, артыҡ өйдәге байтаҡ эшләрне белмибез ий әле: йөн ирләргә белмәдем мин ғүмергә, белмәдем, өйрәнмәдем, мин мендәр тышлар гел вышивать итәм, ә шушы ҡәйнәм, энкәй инде, гел ирләде, но бәйләргә өйрәнеп, щүлкәбаш бәйлейм алай, ойоҡбаш, гетра, ирләргә ғүмердә өйрәнмәдем, гел ҡәйнә ҡарщыҡ үзе бәйләде, ирләде, мин мендәр тышлар, шулай дорожкалар вышивать иттем гел, әллә нищә пар мендәр тышлар, минең мында юғарыда торған бер төрлөсө бар әле, күп нитеп булмый, ошо булған щаҡта, вышивать итеп, ҡырҡ-иллене генә

ниткәнмендер дә, ҡырҡ-илле пар ғына, анда киләм, фермаға, фермадан ҡайтҡащ, кищ буйы ултырасың вышивать итеп, тағын эшкә щығып китәсең. Мынсы ищкесе генә әле, яңыларын, ҡызлар, оноҡларым бар, аларға бирдем. Бер ауылдан, үзем дә шушы ауыл, ирем дә, ҡушылдыҡ та, берәү генә безнең малай. Тоже ауылда торалар, малай буровойда, нефтяный промыселда электрик булып, шунда техникум бөтөп, шунда уҡыды, шунда керде, армияға киткәнще, практикала булды, азаҡ ҡайтҡас, тағы шунда барды. Киленем – уҡытыущы, балаларны уҡыта да, завуч та. Аларның инде тоже ауылда торалар балалары, дүрт-биш балалар, әле без ҡарт ҡартәней, ҡарт ҡартәтей. Быйыл ғына шул зур внучкам балалары булды, малай, оноғобозноҡо балаһы, килендә торалар. Хәзер бындадыр әле алар. Инде өщөнщө айға ғына китте әле, кещкенә. Килендең әле тағын кейәү алып ҡайтып ҡуйзы әле, жылы сыу юҡ әле пока, тип. Улым ғаиләсе белән мында торалар, ә киленнеке уҡытыу мәктәп Бөрөжлөдә, шунда автобус белә балалар белә шунда йөрөй. Улыбыз бар, лечебное правода, этнә эшлей дә, этнә өйдә. Әйвәт торалар. Аллаға шөкөр әле, үзебезнеке дә. И көннәре дә тыныщ булсын ие әле, шуңа эщ боша, и быйылғы жәйгә, күңелсез жәй, жиләк-жимеш йоҡ, шартлама жиләк йоҡ, ҡайын себеркене бавай ана алып уже әзерләп ҡуйды утыз куст, етә миңә ошо, ти. Кеше сатмаға йөрөйләр, безне Хозай, әнә, пенсийәдән айырмасын, безгә пенсиябыз да етә икебезнеке, артыҡ. Ҡаршауылда йөрөйбөз шунда, баҡща утап, баҡщада жукларны щүпләп, әле бүген дә шуңа щүпләп кердек әле, бер аз бар, дарыулап утыртсаҡ та, яңғыр булмаса да, щүп үләннәре щыға, әле ярай өшөп киттеләр әле, теге минус биш градуста бөтөн сабаҡлар янып, бәрәңге-салатлар, ике төр ҡабаҡлар, яңыдан щығып, йәшәреп киттеләр әле. Но яңғыр жуҡ инде бездә, кищә дә килде был яҡтан, теге яҡтан китә, без уртада ҡалабыз да китәбез, бездә яңғыр юҡ, әз генә сибәләп алды былый, шунсына шөкөр итеп торған булабыз инде. .. Алмалар бөтте дүрт төп, алмағащларыбыз йыл да күп алма бирәләр ие, быйыл вообще юҡ, барына да ҡырау тейеп китте. Ҡарағатлар бар. Ярай, булғанына шөкөр. Өмөжө, әнә, баҡщада кищә ҡарап жөрөдөм, үсә торған түгелдер у, тоже эссе ҡысты микән аны, әле ишеткәйнем, Пермдә саталар өмөжө жиләге, тип, малина, аңлыйсыздыр. Жиләк тә, ней дә юҡ бездә вообще. Менә ҡырау да теймәгән жирдә, жауын яуған жирдә да бардыр инде. Бездә бөтөнләй, ярар, бәрәңгеләр үсә, шул безгә. Ащыҡ ауыз ащына белмәс. Үзебезгә Хозай сәләмәтлек бирсен, ил көннәребез тыныщ булсын, суғыш бөтсен бөтөнләй. Элеккеләр кебек ащлыҡлар булмасын.

*– Милли йолаларҙан нимәләр һаҡланған ауылығыҙҙа?*

– Милли йолалар, тип, сабантуйлар була инде, жыен, дин бәйрәмнәрен үткәреп барабыз, әле генә әле ҡорбанлыҡ щалдырып жыйдыҡ, егермеләп безнең ауылдан, теге кафеға шунда бер аз барып биреп, кафеның хужасы, шунда жыйылып сиксәнгә яҡын кеше ҡорбанлыҡ ашлары үткәрдек. Әйвәт булды, кеше күп булды, муллалар, үзебез ауыллар. Дини йолаларны үткәрәбез, намазлар уҡыйбыз уразалар уаҡытта, былый мәщет бездә эшләп тора, харизмға жыйылабыз ун бишләп, элегерәк егермеләп тә була ие, илләр инде азайып баралар, үлеп баралар. Мәщеттә мин үзем аҡща эшләрен алып барам, аятлар уҡыйбыз искещегә, уҡырға өйрәндек, элекке Рәсилә тигән апа уҡывалып, ана, барыбызға өйрәтеп ҡуйды. Аллаға шөкөр, ансын беләбез әле, үзебезгә житәрлек. Муллабыз Бөрөжлөдән килә, үзе Үдикнеке, элекке бывший офицер, бик әйвәт, хөрмәт итәбез, аңҡы хөрмәтендә без дә менә шулый мәщеткә дә йөрөйләр, дин йолаларын барын да үтәп барабыз инде үткәреп, Ураза бәйрәмнәрне, барсын да.

*– Бер таҡмаҡ йырлап ишеттергәйнегеҙ, тағы берәй төрлөһөн йырлап күрһәтегеҙ әле?*

– Таҡмаҡлар күп у, үзем мәщеткә дә, клубка да жөрөйөм, әле сабантуйда да жырладым да, бейедем дә. Инде ҡартайып та барам, тауышым да икенще төрле, тип әйтәм, апа, апа, төш әле, төш, тип торалар инде, кеше ҡая щаҡыра, шунда барам, пока таза щаҡта, аяҡларым жөрөй, даже отказать итеп булмый. Ҡунаҡ жыры жырлыйым микән, ниндей жыр жырлыйм икән? Әле генә сабантуйда мин ней жырладым, “Туған ауыл” тип әйткән.

Ҡайтмыйм тиеп щығып киткәннәр дә
Кире ҡайтып сиңә сыйына.
Ҡабат ҡайттым сиңә, туған яғым,
Щиттә йөрөй-йөрөй арыдым.
Синдә үткән йәшлек йылларымны,
Шишмә сыуларыңды сағындым,
Ҡайтмыйм тиеп щығып киткәннәр дә
Ҡабат ҡайтып сиңә сыйына.
Торған жире матур күренсә дә
Туған жире кире кешегә.
Ҡайтмыйм тиеп шығып киткәннәр дә
Ҡават ҡайтып сиңә сыйына.
Торған жире матур күренсә дә
Туған жире кире кешегә.
Ҡават ҡайттым сиңә, туған яғым,
Синдә генә таптым бәхетне,
Шу бәхетне жуймай йәшәй алсам,
Булыр инем бик тә бәхетле.
Ҡайтмыйм тиеп щығып киткәннәр дә
Ҡабат ҡайтып сиңә сыйына.
Торған жире матур күренсә дә,
Туған жире кире кешегә.
Ҡават ҡайттым сиңә, туған яғым,
Инде ташлап щығып китмәмен.
Син көщ бирдең миңә йәшәр өщөн,
Мин дә сине йәтим итмәмен.
Ҡайтмыйм тиеп щығып киткәннәр дә
Ҡабат ҡайтып сиңә сыйына.
Торған жире матур күренсә дә,
Туған жире кире кешегә.

*– Афарин, бик матур итеп йырлайһығыҙ!*

– Бейеп китәм аннары. Анда тауышлы түгел ие лә, мында ҡыщҡырып жырладым әле, урамнан үткән, мында тауыш ишетелә, тиерләр. Бейеп тә ҡуйдым, йәрмәк көйгә бейеп тә ҡуям мин. Анда мин жырларға щыҡсам, бийергә щыҡсам, минең белән йәшләр щығып жыялар, ооо, Гөлфизә апа щыҡҡан, тип, бийергә, жырларға шунда, ауылда бийеп торалар бары да сәхнә алда, рәхмәт төшкөрләре, рәхмәт, Аллаға шөкөр, уважать итәләр әле.

*– Йәрмәк көй нимә була ул?*

– Йәрмәк көй, Йәрмәк моңо тигән нейгә нитәм мин, татар көйө инде у, татар бийеү, шуларға да биейем, былар белен, йәшләр белен дә биедем, хәзер аларға ҡатышмыйм, анда айырым үзләренеке биеү ансамблләре, инде, мәйтәм, ҡартайдым, сезнең белән йөрөмейм,

тип. Үзем генә шунда. Мәзәниәт йортонда мында әйвәт алый, ҡызлар йөрейләр, биейләр дә жырлыйлар да, үзебездә артислар, молодцы, концертлар әйвәт была. Алый ауылда безнең күңелсез түгел, кеше әйвәт, дини йолаларны үтәп баралар, динле халыҡ, эш сөйөүщән, фермерлар да бар бездә. Элекке колхоз хәзер йәнә шундый, игенләр басыуларда үсеп утыралар, ағащ үсеп утырмый, мал ҡарыйлар, фермалар бар, бары да бар алый. Әле әйвәт кенә. Но тормаған йортлар күбәйә инде. Безнең урам – иске урам инде, бу йортлар уже материнский капиталға алалар да, килеп тә ҡарамыйлар, утыралар шунда кәкрәйешеп. Яңы йортлар бар теге урамнарда, таш йортлар анда, йәшләр тора, без мында ололар ғына, ҡайсында тормыйлар да әнә. Элек бик әйвәт йәшәдек, хәзергесе дә Аллаға шөкөр, олоғайып ҡына барабыз, бер дә әле олоғаясы, ҡартаясы килмей, тыйындырып ҡуялар әле, әле сезгә олоғаясы әле, икегез дә йәш күренәсегез, сиксән дә юҡ әле сезгә, тип, бавай минән биш йәшкә оло у, сиксәнгә житеп килә, йәш щаҡта медалләр алып жөрөдө, лыжник бавай, әле лә жөрөй ярышҡа, элек күп жөрөдө медалләр, урыннар алып. Күңелсез йәшәмейбез алый, әйвәт кенә йәшейбез. Бик шәп, бай йәшәмәсәк тә, булғанына шөкөр. Әле безгә үткән йыл икебез бергә йәшәүгә илле йыл тулды, безгә шулый медалләр бирделәр.

*Сөжән ауылында Уразова Гөлсирә Мәғрүф ҡыҙынан (1952 йылғы)*
*һәм Уразов Рәмис Төхфәт улынан (1947 йылғы) яҙып алынды*

## Төңгөк ауылы







**Максеева Гөлзәмиә Әхмәт ҡыҙы, 1950 йылғы**



Мин Максеева Гөлзәмиә Әхмәт ҡызы. Житмеш өщ йәш. Ғөмер вуйына мәктәптә эшләдем, сыңыдан садикта. Баҡща мөдире булып эшләп пинсийәгә киттем. Бу үзебезнең «Сердәш» группасында ойошторущы, анда Фирза апағызны этеп-тертеп, йәрдәм итеп йөрүще. Мин дин буйынща уҡытам ауылда, үземнең хәзерге уаҡытта егерме сигез уҡущыларым бар диндә, үзем дә дин тотам, безнең зат динне зат инде.

Мин үзем Көнгүр яғынан. Бу Барды районға, уҡып щыҡҡащ Пермдә,уку йортын бөтергәщ, мында эшкә жибәрделәр. Бу алтмыш жиденще йылда килдем мин мәктәпкә эшкә, пионервожатый булып килдем, анан уҡыта башладым. Шул, биш балаларым бар, барсы да юғары белемле, Аллаға шөкер, эшләре бар, ҡайсы икене бөтерде, икешәр юғары уку йортын, барсы да исән, Аллаға шөкер. Беренще майда барсы да жыйылдылар.Шушы ойошмада ««Сердәшләр»» ойошмасында уйыннар, нәрсә дә булса инде планнаштырып, Фирза апасы белән, Фирза апасы минең белән киңәшләшеп эшлей инде. Мин икенще төрле әйткәндә, завуч по воспитательной работе группада, шушыларны тәртипкә саҡлап ҡызларны. Нәрсәдер эшләргә кәрәк тип, шул олораҡ булғащ, ойоштороп жөрөйөм инде, оло булсам да, алардан ҡалмыйым, бәйрәмнәрдән дә ҡалмыйым. Йыл сайын тип әйтерлек үзебезгә костюм, быйыл яңа костюм белән сабантуйда щығыщ ясадыҡ, бик матур былды үзебезнең, барыбыз да бер төсле былғащ, щитекләр, яулыҡлар кейеп, матур итеп ойоштордыҡ, соңыдан фотосын да күрсәтерем әле сезгә, ҡарап нейтәрсез.

Ауылда, шушы кылубта без генә кый ун алты гыруппада без, «Сердәшләр» группасында, барыбыз да жуҡ. Туған көннәрне үткәрәбез, дини бәйрәмнәрне үткәрәбез, барысы да жыйылышып. Кылубта нииндейдер мероприятие булды исә, ҡызлар әйтәләр, үзләре безне әзерлейләр, жырлаталар, бийеүщеләрне бийетәләр, без аларға берсен дә ҡарышмыйбыз. Спортивный праздникларда ҡатнашабыз без, нищек тә әйткәндә, ауылның

щестын күтәрергә тырышабыз. Ҡызлар барысы да юғары белемле былмасалар да, алар барысы да теләп йөрөйләр пинсийәдә, балалары да риза аларның шушында йөрөүләренә, сөйөнәләләр. Апа, син йөрийсең ойоштороп барысын да тип. Мин организаторский диплом алғащ, минке нищектер шунан үзенән-үзе килде ул йәщ щаҡтан башлап, нищектер үзем дә сизмәгәндә ойоштора башлағанны сизмей дә ҡалам инде. Шул, ҡызларым тәртипле барсы да, кылупны шушы яратабыз инде, башҡа кылупта кеүек тарҡау түгелбез, без гел призовой урыннар алабыз. Мин Фирзаға әйтеп жибәрәм, Фирза, беренще урын алма, беренще урынны алсаң, жауабы күп була, ҡунаҡлар сыйлайсы бар, тип, гел икенще урын алып ҡайта, бүләкләр алабыз без, рәхмәт хатлары. Нищек тә кешене тартасы килә шушында, пинщийәгә щыҡкас, арлы-бирле йөрейләр суҡлығып, ҡая китмәгә белмей йөрөгән щаҡларда инде шушында кылупҡа килеп инде, апа, безне дингә үрәт әле тиб әйтәләр, мин ҡаршы килгәнем жоҡ. Берне генә булса да, йылның буйына уҡытам мин уларны, щөнки аларның пинщийәгә щыҡкас, эшләре пошоп тора, ҡаядыр төрлещә төрле нащар юлға китмәсеннәр тип, мин, теләкләре булды исә, дингә тартам аларны, дингә тартҡан кеше тәртипле была инде, щуның өщөн алар, мике ҡызлар, барысы да шундый тәртипле, Ҡөрьәнне уҡып щыҡкан ҡызлар икещәр-икещәр ҡабат, бу апаларың шаян былсалар да, алар дин дәресләре булса, бик серьезный утыралар инде. Нищектер башҡорт былғащ, тәртипле былмаға тейешлебез, шуның өщөн шулай килгән ул элегелектән. Мин бу яҡныҡы булмасам да, килгәщ үк шушы яҡның аксенты белән сөйләшмәгә өйрәндем. Ну, шулай да ҡай щаҡта килеп щыға инде, сорыйлар, апа, син бу яҡныҡы түгелме, тип. Үзебезнең яҡныҡы аксенты килеп щыға. Бездә, Көнгүр яҡта, икенще төрлөрәк сөйләшәләр, күрәсең, мында килгәщ инде, мында икенщерәк. Мике рус ҡатыш үстек без үскәндә. Уҡып щыҡкас та, мине рус районға жибәрделәрей, әней мәрхүм жибәрмәне. Руслар булып үстегез, башҡорт-татар районға бар тип. Шушындай язмыш былғас инде, башҡорт-татар Барды районына килдем инде мин. Башҡортлар тип, ә мике инде национальность рус арада үткән татарка тип язылған. Ә ней булса да үземне башкирка тип яздыртам мин. Хәзер инде илле йылдан да күберәк мында торғащ. Сөйләшүләргә ҡарағанда инде, мин мәктәптә дә эшләгәс, бик шәп ауыл теле белән бик шәп сөйләшеп китәлмәгән щаҡлар да была инде. Минең балалар Татарияда өщөсе биш баланың өщөсө Татарияда торалар. Алар кебек тә сөйләшәп ҡуям, алар яҡҡа барғащ, ғәйнәщә дә сөйләшәм. Щиләкне бездә анығы бидрә тейләр инде, Төнгүктә бидрә тип сүләшәбез, башҡортта да гөмбәне мәшкә тип язалар, ә мин интернеттан уҡыйбыз инде, мин ҡарыйм, интернетта да утырам мин, группада да нейтеп-нейтеп, барсында да современный булмаға тырышам, белмәгәнне балалар ҡайтса, алардан өйрәнәм, ҡызларны өйрәтәм инде, тартам, мәйтәм, нищек тә артта ҡалмаға ярамый, тип.

Күәнтә тип әйтәбез, ҡая барасың тип, утыр әле, тип барысы да безнеке, нейтеп. Башҡортҡа яҡын безнең сөйләм, күп сөйләм, ҡәртәней тип әйтәбез әнә ҡый без. Мике Татариядәге оныҡлар шу бары ҡәртәней тип әйтертләр, анда әбей-бабай тейләр, мике ҡызлар бездә ҡартәней тип әйтәләр тип, оныҡларым ҡартәней тип әйтәләр. Шәһәрдә үсһәләр дә, ҡартаней, ҡартәтей тип сүләшәләр инде. Шундый сөйләм теле башҡорттан бик шәп айырмасы күп түгел. Мин башҡорт телне яратам, жырын да яратам, һ хәреф белән сөйләшкәннәрен. Нищектер күңелгә яҡын ул, нищек, белмейм. Ҡайы бер сүзне аңлаталмаған жирләр была, шул һ хәреф белән сөйләшкән кешене бик шәп яратам инде мин. Жырларын да яратам мин матур итеп, интернетта да ҡарыйм мин постоянно, күңелгә яҡын.

Ҡайтҡас, мында сүлейм мин башҡорт Татарияда да ул хәтле түгел башҡортноң щисталығы, анда посадка буйда бер ағащ аумас, ағащ ауса, анда эшләвйөрөгән кеше була,

щистарта. Бездә татар район ҡайтҡас, әйтәм мин, анда ағащларны төбен сорлап жыйғаннар посадка буйда ап-аҡ, шундый щиста, шундый матур. Башҡортны шуның щисталығы өщен яратам мин аны. Ул районға барып керәсең, бу татар икәнен әллә ҡайдан күренеп тора. Былар мосолманнар, щиста, бөхтә, ә мында безнең безнең дә бар, үзебез башҡорт тип йөрейбез мында, төрлесе бар анығы шундый, ҡайттың исә, шунда щығыщта әйтәм, сез берәттә Башкирияда былғанығыз юҡ, берәт барсағыз, мәйтәм, оялырсыз әй. Андағы щисталыҡҡа, анда силсәүитләрнең матур итеп щитәннәрне бер төскә буяп ҡуйыуларына, әнә мин шул яҡларына ҡызығам башҡортноң, башҡортноң тырыш икәнлеге. Бездә татарлар да тырыш, барыбер русларға ҡарағанда татар халҡы, башҡорт халҡы тырышыраҡ, эшләп тапмаға ярата. Без ғөмергә эшләгән кеше инде, эшләмәсәк, үләрең төслө была инде хәзер. Пинщийәгә щыҡҡас, аҡща житәр микән тибез, хәзер инде аҡщасы да житә, Аллаға шөкер, әйбер дә күп кәрәкмей, былған ғәйепне белгән жоҡ, элек эшләгән әйберләрне.

Мин үзем дә сигез балалы семьяда үстек без үскәндә. Әтей-әнейләр бик тәрбиәле кешеләрейе, Аллаға шөкер, барыбыз да тәртипле былып үстек тип уйлыйм, барыбыз да, абыйларым да уҡымышлы булды, шулый юғары уҡыу йортларын бөтерделәр. Үзем дә ҡарышмадым, бишесен дә бөтерттердем, бишесе дә теләкләре бар икә. Берсе Әлмәттә инде хәзер, кандидат медицинских наук, Мәскәүләрдә бетереп, барысы да Аллаға шөкер. Тырыштылар, сез дә тырышың, уҡыған кеше алда была. Мике ирем үлде, игезәк малайларым бар, өщөнщөсен тапҡанда, икене малайлар таптым да, Пермдә дүрт йыл медколеджда уҡыдылар башта, шунда аҡща сурыйлар инде, ул щаҡта мындый карта белән аҡща жибәреп булмый, шофер белә жибәрәбез, сурыйымей, аҡща жибәр, ней сорағаннар уланнар, бирәбезме тип. Бир, бир тип әйтәйе, мин үзем дә әтей уҡымаға итеп ҡуйды, уҡымый ҡайттым, хәзер гараж буйда жөрейм, майға буялып тип, ул гаражда зав гараж былса да, үзен барыбер уҡымышлы итеп санамыйе, бик грамотные, уҡысыннар тиде, уҡыған кеше алда была, тип. Йөремәсеннәр майға быялып тиде, аҡща бир тип әйтте. Без ауылда нищек тә торабыз тип, ике игезәк тә медицинскийны бетерделәр колледжны, анан академияларын беттеләр, икесе дә медиклар инде. Уҡыған кеше алда была, тырышың, башлаған эшегезне. Мике ҡыз хәзер Алабуғадағысы журналистикаға керәбез тип бардығый без, Алабугаға барған щаҡта, анда нищектер ыудылар-жыудылар безне, рус теле, татар теле группасына этеп кереттеләр безне, Пирем яҡныҡылар, Татариянекеләр үзнекеләр күберәк былғас, видимо, журналистикаға кеше күп былғандыр. Анан мында мике Энже исемле ҡыз инде, уҡытыущысы да рус теле уҡытыущысы әйтә инде, үземнең бер йәш инде без аның белән, Гөлзәмиә, бетерсен юғары уҡыу йортын, тырыш, алып бар, тип, Татарийәгә, аны ҡый ҡызны алып бардым, шунда экзаменнарны бергә биреп ятып икәүләшеп, жәй генә щыҡтым да киттем ҡызны ҡыуалап. Экзаменнар биреп уҡымаға керде. Шундый, тырышың, уҡыған кеше урында эшлей, әбейләр әйтмеш, урында эшләмәгә тырышың. Урында эшләгән кешенең аҡщасы да была, дәрәжәсе дә была, үзегезгә дә приятно была, жигетләр дә уҡығанырағны ҡарыйлар, үзләре дә, үзегез дә уҡығанырағны эзләмәгә тырышың. Үзегезгә тиң былсын. Уҡымаған барыбер икенще терлерәк была, ҡарашы да икенще была, аҡщасын да азыраҡ алса, семьяда тауыш была. Тырышып-тырышып уҡымаға тырышың. Бик уҡымаға мөмкинщелегегез бар, Ходай тәғәлә, әтей әнейләрегез исәндер, бармы әтейләрегез, әнейләрегез, вот аларға исәнлек бирсен инде сезне. Мике килен сезнең кебек журналист, Әлмәттәгесе, игезәкнең сыңары, мында нейгә, интернетҡа ҡуя, постоянно ҡарыйым, журналист, аннан кещкенә телевизордан сөйлей, барып ҡайтҡан кебек былам Әлмәткә. Шул, шундый хәлләр, исән сау, Ходай тәғәлә сезгә тазалыҡ бирсен, сез бигерәк современный

